ДҮШӘМБЕ
12 ФЕВРАЛЬ
1940 ел
№ 35 (5835)
Аерым номеры 10 тиен

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЙЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) Өлкә Комитеты, Шәһәр Комитеты, ТАССР Верховный Советы һәм Шәһәр Советы органы.

РЕДАКЦИЯ АДРЕСЫ:
Казан, Матбугат йорты.
ТЕЛЕФОННАР: экономик бүлек 18—22, авыл хуҗалыгы һәм совет төзелеше бүлекләре 4—58, партия бүлеге һәм матбугат күзәтү бүлеге 14—75, хатлар бүлеге 21—28, культура бүлеге 18—22, информация бүлеге 5—86, төнге редакция 3—75, типография 36—60, бухгалтерия һәм игланнар бүлеге 2—19.

Кызыл Армия еллыгы алдыннан

23 нче февраль көне гүзәл традицион бәйрәм көне булып әверелде. Бу көнне безнең бөтен ил, бөтен халкыбыз данлыклы Кызыл Армиянең һәм Хәрби Диңгез Флотының җиңүләрен чиксез зур шатлык һәм горурлык белән искә төшерә, үзенең җиңелмәслек армиясенә һәм флотына чиксез мәхәббәт тойгыларын күрсәтеп демонстрация ясый, тантана үткәрә.

Дөньяда бердәнбер булган социалистик дәүләтнең коралль таянычы—Кызыл Армия үзенең яшь башлаган көннәреннән алып искиткеч гүзәл юлны үтте. Партиянең һәм хөкүмәтнең, иптәш Сталинның һәм бөтен совет халкының игътибары нәтиҗәсендә безнең армия бөтен дөньяда иң куәтле, иң бай техникалы армиягә әйләнде. Эшче-Крестьян Кызыл Армиясенең һәм Хәрби-Диңгез Флотының көче шунда: алар безнең илдәге бөтен халыкның мәхәббәте белән чолганып алынганнар. Совет дәүләтенең җиңелмәслек булуы шуннан гыйбарәт ки, сугышчан тревога сәгатендә бөтен совет халкы үзенең Ленин—Сталин байрагы астында үз Ватанының изге чикләрен саклауга хәзер.

1940 нчы елның 23 нче февраль көне—Эшче-Крестьян Кызыл Армиясенең данлыклы XXII еллык юбилее көне—узган еллардагы шикелле үк, бөтен халыкның аеруча шатлыклы һәм тантаналы бәйрәме булып үтәчәк. 183 миллионлы халыкның бәхетле тормышын саклаучы армиябез һәм флотыбыз соңгы вакытларда үзләренең тарихларына искиткеч гүзәл сәхифәләрне яздылар. Хасан күле районында һәм Халхин-Гол елгасы буенда, Көнбатыш Украина һәм Көнбатыш Белоруссия хезмәт ияләрен поляк паннары изүеннән азат итү көннәрендә Кызыл Армия сугышчылары мәңгелек дан казандылар. Маннергеймнар һәм Таннерлар коллыгыннан котылу өчен көрәштә Финляндия хезмәт ияләренә ярдәм күрсәтүче Ленинград Хәрби Округы сугышчыларының һәрбер хәрәкәте тиңдәшсез батырлык һәм геройлык белән алып барыла.

СССР ның күп миллионлы яшьләре, Ватаныбызның турылыклы патриотлары, бөтен халык белән берлектә, илнең оборона куәтен көннән-көн ныгытуны үзләренең беренче һәм төп бурычлары итеп саныйлар. Чиксез патриотлык рухында тәрбияләнгән яңа буынның һәрбер вәкиле Советлар Союзы Геройлары шикелле булырга, ак финнәргә каршы көрәш фронтында искиткеч геройлыклар күрсәткән Павел Усов һәм Дмитрий Балаханов, Александр Белогуров һәм Федор Вершинин, Харламов, Трипольский һәм башка бик күпләр шикелле булырга ашкына. Ак финнәргә каршы көрәш фронтындагы сугышларда бу геройлар Ватанга һәм аның юлбашчысы иптәш Сталинга үзләренең чиксез мәхәббәтләрен күрсәттеләр. Алар шикелле булу, илебез файдасына бөтен көчеңне бирү—ул, мобилизацион хәзерлекне көн саен ныгыту, дошманнарга каршы рәхимсез көрәш алып барырга һәр вакыт хәзер тору дигән сүз.

Данлыклы армиябезнең һәм флотыбызның XXII еллыгын без илгә лаеклы бүләкләр хәзерләү белән каршыларга тиешбез. Бигрәк тә Осоавиахим һәм физкультура оешмаларының бөтен эше мобилизацион хәзерлек билгесендә алып барылырга тиеш.

Илнең барлык почмакларында данлыклы юбилейне каршылауга киң хәзерлек бара. Предприятиеләр, колхозлар, МТС лар, совхозлар, уку йортлары Кызыл Армия һәм Хәрби-Диңгез Флоты еллыгын яңа рекордлар белән, социалистик ярышның яңа күтәрелеше белән, укуда яңа казанышлар белән каршыларга хәзерләнәләр. Меңнәрчә хезмәт ияләре хәрби эшне үзләштерергә, хәрби белем алуга омтылалар.

Партиянең үзәк органы „Правда“ үзенең 8 нче февральдәге баш мәкаләсендә, партия оешмалары халыкның оборона мәсьәләләре белән торган саен күбрәк кызыксынуын канәгатьләндерергә тиешләр икәнлекне күрсәтте. Эшчеләрнең, колхозчыларның, интеллигенциянең җыелышларын оештырырга, аларда Кызыл Армиянең һәм Хәрби-Диңгез Флотының тормышы һәм героик эше турында сөйләргә кирәк. Гражданнар сугышында, Хасан күле һәм Халхин-Гол елгасы буендагы сугышларда, Көнбатыш Белоруссиядә һәм Көнбатыш Украинада булган сугышларда катнашучыларның халык белән очрашуларын һәм беседалар оештырырга кирәк. Большевиклар партиясенең хәрби эше турында, Кызыл Армияне һәм аның җиңүләрен оештыруда Ленинның һәм Сталинның гаять бөек роль уйнаулары турында, гражданнар сугышы геройлары һәм Советлар Союзы Геройлары турында, Кызыл Армиянең сугышчылар составын цементтай итеп ныгытучы куркусыз комиссарлар турында киң массага яхшылап сөйләргә кирәк. Большевистик комиссарлар—Сергей Миронович Киров, Серго Орджоникидзе, Валериан Куйбышев турында, пролетар полководецлар һәм командирлар—Фрунзе, Ворошилов, Буденный, Котовский, Пархоменко, Щорс турында сөйләргә кирәк. Аларның үрнәкләре Ватан өчен сугышларда совет халкын һәр вакыт батырлыклар эшләүгә рухландырырга тиеш.

Татарстанның Осоавиахим һәм спорт оешмалары Осоавиахимның ату спорты буенча бөтен Союз күләмендә читтән торып үткәрелә торган ярышларында катнашалар. Һәр җирдә „ГТО“, „ПВХО“, „ГСО“, „Ворошиловча атучы“ һәм башка төрле оборона значокларына нормалар тапшыру бара. Кызыл Армия көненә хәзерлек барышында хәрбиләштерелгән походлар, чаңгы һәм граната ярышлары, Кызыл Армия көнендә Казанда, мотоцикл—чаңгы ярышлары, баскетбол блицтурниры, шахмат-шашка буенча очрашулар, үзешчәнлек сәнгате кичәләре, Кызыл Армия өчен сәнгать көчләренең махсус чыгышлары һәм башкалар үткәреләчәк. Кызыл Армиянең һәм Хәрби-Диңгез Флотының XXII еллыгына багышлап үткәрелә торган бу чараларның барсында да киң массаның катнашуын тәэмин итәргә һәм ул чараларны үрнәк төстә үткәрергә кирәк.

Москваның Сталин исемендәге автозаводы комсомолецлары, физкультурниклары һәм осоавиахимчылары, Кызыл Армия еллыгын иң яхшы итеп каршылау өчен мактаулы йөкләмә алдылар. Алар Кызыл Армиягә резервны иң лаеклы итеп хәзерләячәкләр. Алар заводтагы һәрбер призывникның „ПВХО“, „ГСО“, „Ворошиловча атучы“ значоклары алуына, призывникларның 85 процентының „ГТО“ I значогына,—25 процентының „ГТО“ II значогына нормалар тапшыруына ирешү бурычын куйдылар.

Спортның оборона төрләрен иң яхшы итеп үзләштерү—намуслы һәрбер хезмәт иясенең сугышчан бурычы. Автозавод яшьләре куйган бурычларны Татарстан яшьләре дә киң рәвештә тормышка ашырырлар.

Бөтен халык бәйрәме булган XXII еллыкка хәзерләнү күп миллионлы массада яңа энтузиазм дулкыны күтәрә. Бу күтәренкелеккә җитәкчелек итү, оборона эшен тагын да яхшыртуда һәм ныгытуда ул энтузиазмны файдалану—һәрбер оешманың мактаулы бурычы.

КЫЗЫЛ АРМИЯНЕҢ ҺӘМ ХӘРБИ ДИҢГЕЗ ФЛОТЫНЫҢ XXII ЕЛЛЫГЫ АЛДЫННАН

МОСКВА, 11 февраль. (ТАСС). Каганович исемендәге беренче дәүләт подшипник заводының алдынгылары Эшче-Крестьян Кызыл Армиясенең һәм Хәрби Диңгез Флотының XXII еллыгын стахановчы вахталар белән билгелиләр. Инструменталь цехының фрезеровщигы, Таганка район Советы депутаты иптәш Максимов беренче булып вахтага басты. Ул сменага өч норма бирде һәм хәзер дә эшләп чыгаруны түбәнәйтми. Иптәш Бурчиков бүлеге авыл хуҗалыгы машиналары өчен подшипниклар эшләп чыгару буенча 10 нчы февральгә айлык планны 60 процент үтәде.

ЛЕНИНГРАД ХӘРБИ ОКРУГЫ ШТАБЫНЫҢ ОПЕРАТИВ СВОДКАСЫ

10 нчы февральдә фронтта әһәмиятле бер нәрсә дә булмады.

Безнең авиация күзәтү һәм сугыш очышлары ясады.

Чит илләрдә

КӨНБАТЫШ ЕВРОПА СУГЫШЫ

ПАРИЖ, 10 февраль. Кичә кич Парижда иглан ителгән рәсми белдерүдә болай диелә: „Фронтның Мозель белән Саар арасындагы участкысында ике якның да артиллериясе шактый актив хәрәкәт итте. Дошманның чыгышы кире кагылды“.

Иртәнге белдерүдә „Фронтта бер нинди яңалык булмады“ диелә.

БРЮССЕЛЬ, 10 февраль. „Журнал“ газетасының хәрби күзәтүендә болай диелә: „Көнчыгыш районнарда башланган җылы һава Рейн суының 3 метрга күтәрелүенә сәбәп булды. Шул уңай белән Мажино һәм Зигфрид линияләре тармакларында көчле су басу булмасын өчен кирәкле эшләр үткәрелә. Диңгездә немецләрнең су асты көймәсе тарафыннан бер карабның батырылуыннан башка әйтерлек бер нәрсә дә булмады. Немец самолетлары Англия ярлары өстендә очып йөрделәр“.

БЕРЛИН, 10 февраль. Германиянең информация бюросы хәбәр итә: „Көнбатыш фронтта артиллерия атышуы сизелә. Кайбер пунктларда патрульләр арасында бәрелешләр булды. Бу бәрелешләрдә дошман югалтуларга дучар ителде. Германия патрульләре составыннан яраланган ике кешенең кая икәне мәгълүм түгел. Дошманга каршы разведка операцияләре вактында әһәмиятле мәгълүматлар кулга төшерелде. Германия очучылары дошманның коралланган сәүдә пароходларын Англиянең җиңел һәм уртача сугыш караблары саклап баруны күрделәр“.

Германия армиясенең верховный командованиесе белдерә: „Көнбатыш фронтта әһәмиятле вакыйгалар булмады. Германиянең хәрби һава берләшмәләре, Төньяк диңгез өстендә сугыш разведкасы ясап, Англиянең 6 карабын, шулай ук Англия сугыш караблары конвойлыгындагы барлыгы 15 мең тонна чамасы авырлыктагы корабларны батырдылар. Шулай ук ике сакчылык карабы да батырылды. Зенит орудиеләреннән көчле ут алып баруга һәм истребительләрнең хәрәкәтенә дә карамастан, Германиянең бары бер генә самолеты үз базасына кайтмады. Кичә кич Англиянең кайбер самолетлары Германия бухтасына үтеп керергә маташтылар, ләкин куып җибәрелделәр“.

БЕРЛИН, 9 февраль. Германиянең барлык газеталары Лотарингиядә булган түбәндәге вакыйга турында хәбәр итәләр. Германиянең бер самолетын Германиягә кайткан вакытта Германиянең алдынгы линияләре якынында француз истребителе эзәрлекләп килгән. Кинәт самолетның моторлары эшләүдән туктаган һәм самолет төшә башлаган. Германия пилоты парашют белән сикергән. Шушы моментта аңа Француз истребителе һөҗүм иткән. Француз очучысы парашютчы пилотка өч тапкыр пулеметтан аткан. Пилот берничә җирдән яраланган.

⁂

Германия информация бюросының хәбәр итүенә караганда, Германия гаскәрләренең шушы вакытка кадәр Англия гаскәрләре белән бәрелешкәннәре юк.

Көнбатыш фронттагы пунктларның берсендә француз солдатлары белән немец солдатлары арасында плакатлар ярдәме белән сөйләшү булган. Французларның беренче плакатында немец телендә „Монда французлар“ дип язылган. Германия солдатлары бу плакатны күргәч „Томми кайда?“ дип язылган плакат хәзерләгәннәр. (Томми—Британия солдатларының кушаматы). Җавапта „Англиядә“ диелгән. Германия солдатларының „Алар ни өчен фронтта түгел?“ дигән сорауларына „Алар куркалар“ дигән җавап алынган. Фронтның икенче бер участкысында берничә Француз шулай ук плакатлар ярдәме белән „Сездә эшләр ничек?“ дип сораганнар. Немецләр, Төньяк диңгездә Англиянең күп кенә караблары батырылганлыкны хәбәр иткәннәр. Аларның бу сүзләренә „Шулай булырга тиеш тә“ дигән туры җавап алынган. (ТАСС).

АМЕРИКАНЫҢ НЕЙТРАЛЬ ИЛЛӘРГӘ СУГЫШ КАРАБЛАРЫ САТУЫ

НЬЮ-ЙОРК, 10 февраль. (ТАСС), „Нью-Йорк таймс“ газетасының хәбәр итүенә караганда, Рузвельт АКШ ның диңгез эшләре министре Эдисонны нейтраль илләргә кораллар сатудан тыш искергән типтагы эсминецларны да сатарга вәкил иткән.

Газетаның хәбәр итүенә караганда, АКШ та шундый 37 эсминец бар. Рәсми кешеләрнең белдерүләренә караганда, АКШ хөкүмәте артык сугыш материалларын барлык нейтраль илләргә сату турында карар кабул иткән.

Ассошиэйтед пресс агентлыгының хәбәр итүенә караганда, АКШ ның диңгез эшләре министре ярдәмчесе Комптон, диңгез министрлегенең сугыш карабларын сатарга теләве икеле, дип белдергән. Ләкин, агентлыкның күрсәтүенә караганда, рәсми мәгълүматлар буенча, үткән елның 30 нчы июнендә, сату өчен билгеләнгән сугыш карабларының исемлеге төзелгән. Бу исемлеккә 2 эсминец, 1 крейсер, 6 су асты көймәсе, 2 мина заградителе һәм 9 җиңел сугыш карабы кертелгән.

АНГЛИЯ—ФРАНЦИЯ БЛОГЫНЫҢ СУГЫШ МАКСАТЛАРЫ ТУРЫНДА АМЕРИКА ЖУРНАЛЫ

БЕРЛИН, 10 февраль. (ТАСС). Германиянең информация бюросы Америкада чыга торган „Ньюс уик“ журналында көнбатыш державаларның сугыш максатлары турында мәкалә чыкканлыкны күрсәтә. Мәкалә белән берлектә карта да урнаштырылган. Бу картада „Әгәр бу сугышта Англия һәм Франция җиңеп чыксалар“ Германияне бүлү планы күрсәтелгән. Мәкалә Германияне тулысынча бүлү таләбен Франция аеруча яклый, ди. Көнбатыш державаларның сугыш максаты—Германияне бүлгәләү. Германия составында бары тик Көнбатыш Померанияның кечкенә генә өлешләре, Альтмарк, Брауншвейг, Тюрингиянең бер өлеше, Саксония, Ганноверның аз гына өлеше, Гамбург—Бремен, Вестфалиянең һәм Гессеннең бер өлеше калырга тиеш. Бу территория 4 регентлыкка бүленергә тиеш: Померания (башкаласы Берлин), Брауншвейг (башкаласы Брауншвейг), Ганновер (башкаласы Ганновер) һәм Вестфалия. Германия һәм Пруссия дигән исемнәр бетәргә тиеш. Германиянең калган өлешләре союзниклар һәм алар йогынтысы астындагы башка дәүләтләр арасында бүленергә тиеш.

СОҢГЫ СӘГАТТӘ

ПАРИЖ, 11 февраль. (ТАСС). Хәбәр ителүенә караганда, Рейн елгасының ярлары буенда урнашкан казематлар арасында кичә көндез атышулар булган. Төнлә яңа бер нәрсә дә булмаган.

БЕРЛИН, 11 февраль. (ТАСС). Германия армиясенең верховный командованиесе болай дип хәбәр итә: „Көнбатыш фронтта көн тыныч үтте. Германия авиациясе, һава шартлары начар булуга карамастан, Англия өстендә үзенең разведка эшен дәвам иттерде. Германия самолетлары Англиянең бер сакчылык судносын батырдылар. Самолетларның барсы да үзләренең базаларына кайттылар. Германиянең ерак юлдан кайткан бер су асты көймәсенең командиры, су асты көймәсе дошманның сугыш караблары сакчылыгында бара торган, 38.000 тонна су сыйдырышлы пароходларын батырды, дип белдерде“.

БЕРЛИН, 11 февраль. (ТАСС). Трансоцеан агентлыгының белдерүенә караганда, Дарданелга керә торган урында Төркия территориаль суларында Англиянең торпеда катеры тарафыннан Румыниянең „Трансильвания“ дигән пароходы тотылган һәм тентелгән. Англичаннар пароходта Германия гражданнарын нәтиҗәсез рәвештә эзләгәннәр. Англиянең хәрби судносы тарафыннан Төркиянең территориаль суларында ясалган тентү Истамбулның политик даирәләрендә шактый ризасызлык тудырган.

ЛОНДОН, 11 февраль. (ТАСС). Хәбәр итүләргә караганда, 9 нчы февральдә немец самолетларының һөҗүм итүләре нәтиҗәсендә Төньяк диңгездә ике тральщик батырылган. 4 офицер һәм 18 матрос һәлак булган.

Шул ук көнне күп кенә сәүдә пароходларына һавадан һөҗүм ясалган. Бу пароходларның өчесе нык кына зарарланган.

В. Барков һәм В. Лисевич рәсме.

ФРАНЦИЯ ДИҢГЕЗ МИНИСТРЕНЕҢ АҢЛАТУЫ

ПАРИЖ, 10 февраль. (ТАСС). Гавас агентлыгы Франциянең диңгез министре Кампинкиның речен тапшыра. Ул хөкүмәткә сугыш алып баруда һәм сугыш заказларына түләүдә ярдәм итү өчен радио буенча Франция халкын сугыш заемына активрак язылырга чакырган. Кампинки диңгез флотында берничә минутлык сугыш хәрәкәтләренең күпмегә төшүен күрсәтә торган саннар китерә: „Су асты көймәләренә каршы кулланыла торган 200 килограмм авырлыгындагы бомба 6.000 франк, мина—75.000 франк, торпеда—530.000 франк тора. Бер су асты көймәсен батыру өчен Франциянең „Сирокко“ эсминецы 9 бомба җибәрергә тиеш булган. Бу 54.000 франкка төшкән. „Фош“ крейсере орудиеләреннән бер минут эчендә ату 72.000 франкка төшә. „Дюнкерк“ линкоры бер миллиард франктан артыгракка төшкән иде, ә „Ришелье“ линкоры 2 миллиард франкка төште“.

Кампинкинең бу аңлатуларыннан Франция халкы үзенә сугышның күпмегә төшүен һәм ул сугышның капиталистларны баетуын аңлар.

ГЕРМАНИЯДӘ ХАЛЫК ПЕРЕПИСЕНЕҢ БЕРЕНЧЕ ЙОМГАКЛАРЫ

БЕРЛИН, 10 февраль. (ТАСС). Германиянең информация бюросы Германиядә 1939 нчы елны үткәрелгән халык переписенең беренче саннарын тапшыра. Бу саннарга караганда, Германиядә 79.364.408 кеше бар. Бу исәпкә Мемель өлкәсенең, Данцигның һәм көнчыгыштагы яңа өлкәләрнең халыклары керми. 1933 нче ел белән чагыштырганда халык саны 2,9 миллион кешегә, яки 3,8 процентка арткан. Шушы ук чор эчендә халыкның табигый артуы 2,86 миллион чамасы булган. Перепись саннарына караганда 1.000 ир кешегә 1.048 хатын-кыз туры килә, 1933 нче елны исә 1.061 туры килә иде. Бер квадрат километр территориягә уртача 136 кеше туры килә. Германия районнарында халыкның тыгызлыгы бер квадрат километрга 140 кешедән 147 кешегә кадәр арткан. Илдә халыкның тыгызлыгы кимрәк булу элекке Австрия һәм Судет өлкәсе кебек өлкәләрдә халыкның тыгызлыгы кимрәк булудан килә. Берлиндә 4.399 мең, Венада—1.920 мең һәм Гамбургта—1.713 мең кеше яши.

Ак финнәргә ярдәм итүгә каршы

НЬЮ-ЙОРК, 10 февраль. (ТАСС). АКШ та ак финнәргә ярдәм итүгә каршы хәрәкәт көчәя. „Дейли уоркер“ газетасының хәбәр итүенә караганда, Балтимор шәһәрендә күп кенә оешмалар, шул исәптән профсоюзларның җирле советы, Финляндиягә материаль ярдәм күрсәтүгә каршы чыгыш ясаганнар.

„Бикон джорнэл“ газетасы тарафыннан резина промышленностеның зур үзәгендә — Экрон шәһәрендә (Огайо штаты) таратылган анкета да Америка халкының киң массасының настроениесен ачык күрсәтә. Анкетадагы сорауларга җавап биргән кешеләрнең 88 проценты ак финнәргә ярдәм итүгә каршы язганнар.

„Дейли уоркер“ газетасы хәбәрчесенең Сиэттльдән (Вашингтон штаты) хәбәр итүенә караганда, 1.100 кеше катнашкан бер җыелышта кабул ителгән резолюциядә Америка хөкүмәтеннән „киң катлау массаның көндәлек таләпләрен тиз арада канәгатьләндерүне һәм АКШ ны Европа сугышына тарту куркынычын тудырырлык һәр төрле политиканы туктатуны“ таләп итәләр.

КЫТАЙДА СУГЫШ ХӘРӘКӘТЛӘРЕ

(ТАСС хәбәрләреннән)

КӨНЬЯК КЫТАЙДА

Гуанси провинциясенең көньяк өлешендә Наньнин—Циньчжоу шоссесендә каты сугышлар бара. Монда кытайлар берничә пунктны алганнар. Бу сугышларда японнарның 600 ләп кешесе үтерелгән.

ҮЗӘК КЫТАЙДА

8 нче февральдә Чжэцзян провинциясенең төньяк өлешендә кытай гаскәрләре белән япон гаскәрләре арасында кечерәк сугышлар булган. Бу көнне японнарның бер хәрби часте Сяошань районында Цяньтан елгасын аркылы чыгарга маташкан. 40 лап солдатлары үтерелгәннән соң японнар чигенергә мәҗбүр булганнар.

„Нью-Йорк таймс“ газетасы Кытайның сугыш министрлеге вәкиленең белдерүен тапшыра. Вәкил Гуанси провинциясенең көньяк өлешендә, Наньнин секторында кытайлар дивизиясен япон гаскәрләренең чолгап алуы һәм шулай итеп аларны капкынга эләктерүләре турындагы хәбәрләрне инкар итә. Шул ук вакытта ул кытай гаскәрләренең японнарның Наньниннан көнчыгыштарак булган позицияләренә атака ясап Юншуньны һәм Каньтанны алулары турындагы элекке белдерүне раслады. Аннары вәкил японнарның хәзер Биньяннан 30 миль төньяк-көнбатыштарак Шанлин янында тоткарланып торуларын әйтте. (ТАСС).

ЯПОННАРНЫҢ КЫТАЙДАГЫ ЮГАЛТУЛАРЫ ТУРЫНДА СЕНТРАЛЬ НЬЮС АГЕНТЛЫГЫ

ЧУНЦИН, 10 февраль. (ТАСС). Сентраль Ньюс агентлыгының кичә иглан ителгән саннарына караганда, Кытайда 30 ай сугыш дәвамында японнар 1.400 мең кешеләрен югалтканнар. Диңгез флотының, диңгез пехотасының һәм авиациянең югалтулары 90 мең кеше. Үтерелүчеләр яралланучыларга караганда 4 тапкыр күбрәк.

ПАРТИЯ ТОРМЫШЫ

Партиянең җитәкче органнарын сайлауларга хәзерлек

„УРАК һӘМ ЧҮКЕЧ" ЗАВОДЫ ПАРТОЕШМАСЫНДА

„Урак һәм Чүкеч" заводы партоешмасында отчет - сайлау җыелышына хәзерлек эше зур активлык белән бара.

8 нче февральдә партбюро утырышы булды. Бу утырышта отчет - сайлауларны үткәрү буенча төзелгән план тикшерелде. Моңа кадәр булып үткән сайлаулар вактындагы уңышлы һәм кимчелек якларга җидди анализ ясалды. Партоешма секретаре иптәш Хомяков отчет - сайлауларга хәзерлек мәсьәләләре буенча партгруппа җитәкчеләре һәм аерым коммунистлар өчен индивидуаль консультацияләр һәм инструктажлар үткәрә. Партбюро членнары ВКП(б) Үзәк Комитетының инструкциясен өйрәнү һәм отчет-сайлау җыелышларына хәзерлекне оештыру буенча булышлык күрсәтү өчен партгруппаларга беркетелделәр. Алар үзләренә йөкләнгән бурычны үтәү эшенә керештеләр.

Отчет - сайлау җыелышына хәзерлек уңае белән производствода коммунистларның авангардлык рольләре тагын да күтәрелде. Мәсәлән, механика цехының стахановчысы коммунист Яруллин 9 нчы һәм 10 нчы февральдә көнлек эш нормасын 250—300 процент итеп үтәүгә иреште. 10 нчы номерлы цехның стахановчысы коммунист Романов та эш нормасын шулай ук арттырып үти.

Г. Шаһиев.

НАРКОМПРОС ПАРТОЕШМАСЫНДА

Татарстан АССР Мәгариф Халык Комиссариаты янындагы партоешма отчет - сайлау җыелышына хәзерлек эшләрен яхшы гына җәеп җибәргән. Отчет - сайлау җыелышына хәзерлек һәм аны үткәрү мәсьәләләре партбюро утырышына һәм партҗыелышка куелган.

Җыелышка хәзерлек һәм аны үткәрү уңае белән 2 номер стена газетасы чыгарылачак. Газетаның беренче номерында нарком приказларының үтәлешен тикшерү, жалобаларны карау һәм Наркомпроста хезмәт дисциплинасының торышы турындагы мәсьәләләр яктыртылачак. Бу мәсьәләләр буенча рейд үткәрү өчен партбюро Рыжов, Вәлеев, Мельникова иптәшләр җитәкчелегендә, составы өчәр кешедән торган, 3 бригада оештырган.

Стена газетасында, шулай ук партиянең эчке эшләренең торышы яктыртылачак.

Хәзер, партоешманың отчет докладын төзү эше бара. Отчет - сайлау җыелышы 20 нче февральдә үткәреләчәк.

Ишкаев.

С. М. КИРОВ ИСМЕНДӘГЕ ЗАВОДНЫҢ ПАРТОЕШМАСЫНДА

С. М. Киров исмендәге заводның партоешмасында цех партоешма секретарьларының киңәшмәсе үткәрелде. Киңәшмәдә отчет-сайлауларга хәзерлек турындагы мәсьәлә тикшерелде һәм ВКП(б) Үзәк Комитетының сайлаулар турындагы инструкциясе өйрәнелде.

Цех партоешма секретарьлары производствода эшләүче коммунистларны ВКП(б) Үзәк Комитетының инструкциясе белән таныштыралар һәм беседалар үткәрәләр.

Отчет-сайлауларга хәзерлек уңае белән производствода коммунистларның авангардлык роле сизелерлек рәвештә яхшырды. Орденлы иптәш Гаркави җитәкчелек итә торган цехта коммунист иптәш Сөнгатуллин производствода көнлек заданиене яхшы сыйфат күрсәткечләр белән 105 процент итеп үтәп бара. Столярный мастерскойда эшләүче коммунист Тимохин көнлек эш нормасын 180—200 процент итеп үти. Коммунист Горбунов бригадасы көнлек заданиене 150—180 процентка кадәр үтәп килә. Усманов җитәкчелек итә торган цехта эшләүче коммунистлардан Аксенов һәм Гыйлманов иптәшләр дә производствода алдынгылык үрнәге күрсәтәләр.

Хөснимәрданев.

ӘЛМӘТ РАЙОНЫНДА

(Телефон буенча)

Әлмәт районының башлангыч партоешмаларында отчет - сайлау җыелышлары 15 нче февральдән башланачак.

10 нчы февральдә башлангыч партоешма секретарьларының һәм партия оештыручыларының киңәшмәсе булды. Киңәшмәдә ВКП(б) Үзәк Комитетының сайлаулар турындагы инструкциясе өйрәнелде һәм отчет сайлауларга хәзерлек эшенең практик чаралары билгеләнде. ВКП(б) райкомы бу җыелышларны оештыруда башлангыч оешмаларга ярдәм итү өчен райком пленумы членнарын һәм партия активыннан 32 кешене авылларга җибәрде. Хәзер партиянең башлангыч оешмаларында отчет сайлауларга хәзерлек уңае белән җыелышлар үткәрелә. Бу җыелышларда коммунистлар ВКП(б) Үзәк Комитетының сайлаулар турындагы инструкциясен өйрәнәләр.

З. Салахеттинов.

„ШАХТЕР" КОЛХОЗЫНЫҢ АГИТАТОРЛАРЫ

Буденный районы, „Шахтер" колхозындагы (Сук-Су Выселкасы авылы) агитколлектив хезмәт ияләре депутатларының җирле Советларына сайлаулар кампаниясендә гаять зур эш башкарды. Коллектив членнарының эш нәтиҗәләре сайлауларның йомгакларында ачык күренде. Ул коммунистлар һәм партиясезләрнең Сталинчыл блогының яңа, гүзәл җиңүен тәэмин итүче көчләрнең берсе булды.

Бу коллектив колхозчылар арасында зур ышаныч һәм авторитет казанды, үз сафларында колхозның алдынгы кешеләрен яхшы оештыручылар итеп тәрбияләде. Мәсәлән, агитаторлардан иптәш Фәхреттинев бригадир, иптәш Хөсәенев агрономия түгәрәге җитәкчесе һәм иптәш Сафиуллин Осоавиахимның башлангыч оешмасы җитәкчесе булып эшлиләр.

Агитколлектив членнарының яхшы үрнәкләре шунда ки, алар агитация эшен политик һәм хуҗалык бурычларын уңышлы үтәү өчен көрәш белән бергә бәйләп алып баралар. Үзләре производствода алдынгылык үрнәкләре күрсәтәләр. Менә агитатор һәм бригадир иптәш Рәхим Фәхреттинев. Ул колхозчыларны югары иген уңышы өчен көрәшкә чакыра. Сталинград өлкәсе бригадирларының ничек итеп мул уңыш алуга ирешүләрен, Калинин районы авыл хуҗалыгы алдынгыларының мөраҗәгатен колхозчыларга аңлата. Колхозчылар аның инициативасы буенча 1940 нчы елда һәр гектардан кимендә йөз пот иген уңышы алу өчен көрәшергә карар бирделәр.

Алган йөкләмәләрне үтәү өчен көрәшне иптәш Фәхерттинев башта үз бригадасында үрнәк итеп оештырды. Чәчү орлыкларын чистарту, инвентарьга ремонт ясау эше кыска срокта тәгәлләнә. Бригада членнары барсы да үзара ярышып, стахановча эшлиләр.

Иптәш Фәхерттинев бригадасы үрнәгендә колхозның башка бригадалары да югары иген уңышы өчен көрәшне ныклап оештыралар һәм тырышып эшлиләр. Шуның нәтиҗәсе буларак, „Шахтер" колхозы хәзер үк инде, язгы чәчүгә тулысынча хәзерләнде.

Агитаторларның үрнәкле эшләре колхозчыларның политик һәм производство активлыгын нык күтәрде. Политик-агитация эше Сук-Су Выселкасы авылы хезмәт ияләре арасында киң җәелдерелде. Алар партия һәм хөкүмәт карарларын ныклап өйрәнәләр, илебездәге көндәлек яңалыклар һәм халыкара хәл турындагы мәсьәләләр белән бик кызыксыналар. Колхоз уку өе һәр көнне кичләрен колхозчылар белән тулы була. Анда уку өе мөдире, агитатор иптәш Мөнирә Билалова зур эш алып бара. Кайберәүләргә ул, журналлардан һәм газеталардан аерым мәкаләләрне укырга тәкъдим итә, ә кайберәүләренә кычкырып газета укый һәм аңлата.

Партия һәм комсомол оешмалары соңгы көннәрдә агитколлектив составын яңадан бер тапкыр тикшерде һәм тулыландырды. Шулай итеп, хезмәт ияләре депутатларының җирле Советларына сайлаулар вактында киң колач алган политик агитация эше хәзер дә зур активлык белән дәвам иттерелә.

Хәзер агитаторлар ВКП(б) Өлкә Комитетының VIII нче пленумы карарларын һәм авыл хуҗалыгы алдынгыларының республика киңәшмәсе материалларын колхозчыларга аңлаталар. Эшче-Крестьян Кызыл Армиясенең һәм Хәрби-Диңгез Флотының XXII еллыгына карата беседалар уздыралар. Агитколлектив җитәкчесе, мәктәп мөдире Хәдичә иптәш Ильясова планлы эш алып бара һәм агитаторларның көндәлек эшләренә конкрет булышлык күрсәтә.

А. Яфизов.

ВКП(б) райкомнары пропагандистларының өлкә семинары. РӘСЕМДӘ: ВКП(б) Өлкә Комитеты лекторы иптәш Бухараев җитәкчелегендәге семинарның чираттагы занятиесе. И. Галиев фотосы.

ТАССРның XX еллыгына хәзерлек

МЕХЧЫЛАРГА БЕЗНЕҢ ҖАВАП

Житен комбинатының тарау цехы коллективы мехчылар чакыруын зур күтәренкелек белән каршылады. Цех коллективы орденлы Татарстан республикасының данлыклы XX еллыгын производствода яңа җиңүләр белән каршылау өчен, ярты еллык планны югары сыйфатлы итеп 25 нче июньгә үтәргә йөкләмә алды. Моның өчен алдынгы стахановчыларның яхшы эш тәҗрибәләрен уртаклашу оештырыла. Цехның яхшы эшләвенә булышлык итү өчен уйлап табу һәм рационализация буенча күп кенә чаралар тормышка ашырылачак.

Татарстанның XX еллыгы уңае белән алган йөкләмәләрне без намус белән үтәү эшенә керештек инде. Цехка айлык план өч сменада эшләү буенча билгеләнгән иде. Без планны ике сменада эшләп, арттырып үтәүне бурыч итеп алдык. Дөрес, бу эштә башта кимчелекләр булды. Беренче көннәрдә 300—400 килограмм сүс ким эшләнде. Хәзер без бу җитешсезлекләрне бетердек, хезмәт җитештерүчәнлеген шактый үстерүгә ирештек.

Хәзер инде күп кенә эшчеләр яңа норманы арттырып үтиләр. Колпатчикова, Нигмәтҗанова иптәшләр 300 килограмм урнына 420 килограмм сүсне машинадан үткәрәләр. Цехта берничә машинага хезмәт күрсәтү буенча шактый зур эш башкарылды. Элек бер тарау машинасында ике—өч кеше эшләгән булса, хәзер бер кеше дә бу эшне бик яхшы башкара. СССР ның туку промышленносте наркомы иптәш Косыгин приказы буенча бу тәҗрибә Союзның башка предприятиеләрендә дә үткәреләчәк.

Без үткән ел планны уңышлы үтәү өчен комбинатның күчмә кызыл байрагын яулап алдык. Мехчылар чакыруы буенча алган йөкләмәбезне дә намус белән үтәрбез, орденлы республикабызның XX еллыгын производствода яңа уңышлар белән каршыларбыз.

А. Помпеев.

Житен комбинатының тарау цехы начальнигы.

ТАГЫН ДА ЯХШЫРАК ЭШЛӘРГӘ

Серго Орджоникидзе исмендәге завод колликтивы Москвадагы инструменталь заводы коллективының чакыруына стахановча эш белән җавап бирә.

Начальнигы иптәш Андриянов булган цех коллективы алган йөкләмәләрен намус белән үти. Цехның стахановчысы фрезеровщик Губачев, күп станокта эшләүче К. Фирсов иптәшләр норманы 400—500 процент үтиләр. Иптәш Фирсов үзенең стахановча эш тәҗрибәсен уртаклашу өчен күптән түгел генә техник күргәзмә үткәрде. Шуннан соң эшчеләр хезмәт җитештерүчәнлеген тагын да күтәрделәр.

Начальнигы иптәш Тюрин булган цехның Кызыл байраклы мастерское январь ае программасын югары сыйфатлы итеп 21 нче январьда ук үтәде. Иптәш Нотфуллин көнлек норманы 400 процент итеп үти.

Цехның күчмә Кызыл байрагы белән бүләкләнгән мастерскойның иптәш Насыйбуллин бригадасы аеруча яхшы эш үрнәкләре күрсәтә. Бу бригада катлаулы агрегат җыю эшен бик яхшы башкара.

Уңышлар булу белән бергә эштә кимчелекләр дә бар әле. Начальниклары Медведский, Будников, Глазков иптәшләр җитәкчелек иткән цехларда эшләүчеләр эш белән тулысынча тәэмин ителмиләр. Бу цехларда социалистик ярыш договорлары вактында тикшерелми. Заводның производство бүлеге тарафыннан 1940 нчы ел программасы цехларга җиткерелмәгән әле. Шуның аркасында эшчеләрнең күп кенә эш вакытлары эшсез торып үтә.

А. Ялышев.

СТАЛИН РАЙОНЫНДА

Казанның Сталин районында республикабызның XX еллыгы көнен каршылауга хәзерлек уңае белән район Советы башкарма комитеты районны төзекләндерүгә, урамнарга һәм тротуарларга таш һәм асфальт җәюгә, Булакны реконструкцияләүгә (районга төшкән өлешен) һәм торак йортларына ремонт ясауга карата конкрет чаралар билгеләде. Бу гаять зур эшләрне башкарып чыгу өчен 5 миллион сумнан артык акча тотылачак.

Башкарма комитеты, Тукай һәм Нариман урамнарына һәм бу урамнарның тротуарларына таш һәм асфальт җәюне юбилей көненә тулысы белән тәмам итәргә карар бирде.

Орденлы Татарстан республикасының XX еллыгы көненә укый-яза белмәүчелекне тулысы белән бетерү бурычы куелды.

Юбилей көненә Сталин районының элекке хәлен һәм Октябрь Социалистик революциясеннән соң, Сталинчыл бишьеллыклар чорында танымаслык булып үзгәрүен күрсәтә торган күргәзмә оештыралачак. Хәзерге вакытта бу күргәзмәгә материаллар туплау эше башланды.

Полковник С. ШИШКИН

ВОЛОЧАЕВКА ШТУРМЫ

Ерак Көнчыгышның рәхимсез кышы иде.

Волочаевка станциясен кар көртләре басып киткән. Станциядән ике километрда Волочаевка авылы күренеп тора.

Биредә моннан 18 ел элек героик епопея булып үтте. Аның турындагы истәлек халкыбызның йөрәгендә һаман да яши, бөтен СССР да аның турында җырлар җырлыйлар һәм һәр вакыт җырларлар.

1922 нче ел иде. Колчакның һәм Семеновның тар-мар ителгән ак гвардия бандаларының калдыклары Ерак Көнчыгышка, Приморьегә агылдылар. Ак гвардеецлар үзләренең җимерелгән көчләрен япон акчасына һәм япон командованиесе җитәкчелегендә тәртипкә салырга тырыштылар, „ак восстаниечеләр армиясе" оештырдылар һәм аны Ерак Көнчыгыш республикасына һөҗүмгә хәзерләделәр.

1921 нче елның 30 нчы ноябрендә генерал Молчанов армиясе Революцион Халык Армиясе заставаларына ташланды. Сан һәм техника ягыннан өстен булган дошманга ныклы каршылык күрсәтеп, халык армеецләре Хабаровскидан китәргә мәҗбүр булдылар һәм тимер юл буйлап Ин станциясенә чигенделәр.

Беренче уңышлар белән исергән генерал Молчанов „Москвага поход" турында хыяллана башлады. Гражданнар сугышының яңадан башланып китү куркынычы Ерак Көнчыгыш хезмәт ияләре арасында гаять зур күтәренкелек тудырды.

Большевиклар партиясе Үзәк Комитетының Ерак Көнчыгыш бюросы партия членнарына мобилизация игълан итте. Партиянең бөтен Амур оешмасының 50 проценты чамасы Революцион Халык Армиясенә китте. Забайкалье өлкәсеннән фронтка 500 коммунист җибәрелде. Приморье, Амур һәм Забайкалье комсомолы берничә мең комсомолецка һәм эшче яшьләргә мобилизация ясады.

Кышкы көннең гаять авыр шартларындагы кыенлыкларга да карамастан, Революцион Халык Армиясе частьләре декабрь азагында һөҗүмгә күчтеләр. Ин станциясенә якынлашып килгән ак гвардеецларның көчле группасы 28 нче декабрьдә тар-мар ителде. Аның калдыклары Волочаевкага чигенде.

Генерал Молчанов Волочаевка станциясе һәм авылы районында ныгырга, ныгытылган Волочаевка позицияләрендә Революцион Халык Армиясен җимерергә карар бирде.

1922 нче елның январь ае эчендә ак гвардеецлар Волочаевка тирәсендәге позицияләрен ныгыттылар. Алар бик күп окоплар, пулемет оялары ясадылар, 5—6 рәтле тимер чыбык заграждениеләр ясадылар, якын тирәдәге әрәмәлекләрне чәнечкеле тимер чыбык белән чорнадылар. Аклар Волочаевка районының үзен аеруча ныгыттылар, анда иң яхшы командир полковник Аргунов командасындагы офицерлардан һәм унтер-офицерлардан сайланма частьләрне тупладылар. Февраль башында Волочаевка позицияләрен карап чыгып, генерал Молчанов аларны бик нык дип тапты.

Волочаевкага штурм 10 нчы февральгә билгеләнде. 8 һәм 9 нчы февральдә җыелма бригада һәм Забайкалье группасы штурмга хәзерләнде.

10 нчы февральдә иртә белән штурм башланды. Кызыл гаскәрләр тиңдәшсез геройлык белән дошманга ташландылар. 5 нче укчы һәм 4 нче кавалерия полклары Волочаевканы төньяктан әйләнеп үттеләр. Анда алар тимер чыбык заграждениеләренә очрадылар. Аерым Амур полкы батальоны үзенә бирелгән ике танк белән (алар кызыл партизаннар тарафыннан Колчактан сугышып алынган француз танклары иде) тимер юл буйлап Волочаевка позициясе үзәгенә атака ясауга күчте. 6 нчы укчы полк Волочаевкага көньяктан һөҗүм итте.

Дошман беренче атаканы кире кайтара алды. Бригада частьләре карга яттылар. Атаканы яңарту яки заграждениеләрдән чигенү мөмкин булмады: ак гвардеецларның уты шул кадәр көчле иде. Бригаданың частьләрен төн уртасында гына акларның тимер чыбык заграждениеләреннән 600 адым читкә күчерергә мөмкин булды.

Беренче атаканың уңышсыз чыгуы халык армеецләренең җиңүгә омтылышларын какшатмады.

Җимерелгән тимер юл күперләрен 11 нче февральдә кичкә таба дошманның рәхимсез уты астында халык армеецләре төзәттеләр. Бу, ике бронепоезд китерергә мөмкинлек бирде.

Өченче көндә Революцион Халык Армиясенең сугышчылары дошманның тимер чыбык заграждениеләре алдында карда яттылар. 35 градус салкында Волочаевканы томан каплады. Таң атканда бронепоездан ату ишетелде—бу штурмга башлау өчен сигнал иде. Артиллериядән һәм пулеметлардан ату башланды. Сугышчылар кардан тордылар һәм штурмга ташландылар.

Сугышчылар һәм командирлар туңган куллары белән тимер чыбыкларны өзәргә тотындылар, чыбыкларны прикладлар һәм сөңгеләр белән аердылар. Дошманның өзлексез уты астында сугышчылар зур батырлык һәм үз-үзләрен аямаучанлык белән киртәләрне бер-бер артлы җиңделәр. Күп кенә кызыл геройлар үтерелеп һәм яраланып, тимер чыбык заграждениеләр янында калдылар.

Иртән 8 сәгаттә 6 нчы һәм 3 нче укчы полклар тимер чыбык заграждениеләрне кисеп үттеләр, һәм акларның окопларына якын ук килделәр. Монда ак гвардеецларның бронепоездлары кызыл сугышчыларның цепьларын үтеп керделәр. Алар зур югалтуларга очрадылар. Бу урында кызыл гаскәрләр арасына ак гвардеецларның бронепоездлары килеп керде. Алар безнең гаскәрләргә авыр югалтулар китерделәр. Шуннан соң кызыл бронепоезд, ак гвардеецларга ата-ата, дошманның бронепоездларына атакага барды. Аклар артиллериясенең снарядлары пулемет бронеплощадкасын җимерде, паровозга һәм контроль площадкага тиде. Ләкин кызыл бронепоезд атудан туктамады һәм дошманның алда бара торган бронепоездын туктарга һәм чигенергә мәҗбүр итте. Кызыл бронепоезд аклар пехотасына пулеметтан ут ачты. Бронепоезд артыннан пехота кисеп керде, штыклар белән удар ясап, ак гвардеецларны окоплардан бәреп чыгарды. Әйләнеп үтүче колоннаның кавалерия эскадроны акларның тылына керде һәм тимер юл күперен яндырды.

Кан түгүле рәхимсез сугыш 11 сәгаткә кадәр сузылды. Ахрында халык армеецләренең кысрыклавына түзә алмыйча, дошманның пехотасы кача башлады. Волочаевка алынды. Крепость өстендә кызыл флаг күтәрелде. Хабаровскига юл ачылды.

Революцион Халык Армиясе частьләре тарафыннан куылган аклар, Волочаевка янында үлгән 400 кешеләрен һәм яраланган 700 кешеләрен югалтып, Приморьегә, качтылар. Волочаевка һәм Спасск янындагы сугышлар хәл иткеч соңгы сугышлар булды. Ерак Көнчыгыштагы ак гвардеецлар һәм интервентлар калдыкларының тар-мар ителәчәге алдан ук хәл ителде.

Акларның Волочаевка позицияләренә соңгы ударның иң зур авырлыгы 6 нчы укчы полк һәм 8 нче номерлы бронепоезд өстенә төште. Дошман позицияләренә героик атака ясаган өчен бронепоезд Кызыл Байрак ордены белән бүләкләнде. Соңыннан Кызыл Байрак орденлы 4 нче Волочаевка полкы дип аталган 6 нчы укчы полк та Кызыл Байрак ордены алды...

18 ел үтте.

Кызыл гаскәрләр япон интервентларын һәм алтын погонлы ак гвардеецлар өерен Советлар Ерак Көнчыгышыннан мәңгелеккә кудылар. Героик Кызыл Армиянең иң яхшы сугышчылары шуның өчен көрәшкән эш җинде!

1922 нче елның 26 нчы октябрендә В. И. Ленин түбәндәге телеграмманы бирде:

„Җиңүле Октябрь революциясенең биш еллыгына Кызыл Армия РСФСР ның һәм ана күрше республикаларның территорияләрен чит ил оккупантлары гаскәрләреннән тәмам чистартуга таба тагын бер хәл иткеч адым атлады. Ерак Көнчыгыш республикасының Революцион Халык Армиясенең Владивостокны алуы япон империализмының авыр изүен кичергән рус гражданнарын Россиянең хезмәт ияләре массасы белән берләштерә. Бу яңа җиңү белән Россиянең барлык хезмәт ияләрен һәм героик Кызыл Армияне котлап, Ерак Көнчыгыш республикасы хөкүмәтеннән үтенәм: азат ителгән өлкәләрнең һәм Владивосток шәһәренең барлык эшчеләренә һәм крестьяннарена РСФСР Халык Комиссарлары Советының котлавын тапшырсагыз иде.

РСФСР Совнаркомы председателе Ульянов (Ленин)".

АЛДЫНГЫЛАР КИҢӘШМӘСЕ МӨРАҖӘГАТЕН ТИКШЕРӘЛӘР

Без кызу эш башладык

Киңәшмәдән кайткан көнне үк мин колхоз активы утырышында, ә икенче көнне колхозчыларның жыелышында киңәшмәнең йомгаклары турында доклад ясадым. Аннары үз бригадамның активы белән киңәшмәнең мөраҗәгатен тагын бер тапкыр тикшереп чыктым, 1940 нчы елны югары иген уңышы алу өчен нәрсәләр эшләгәнлекне һәм нинди эшләр эшләнергә тиешлекне тикшердек.

Минем 3 нче номерлы бригада быел бөртекле культураларның (бөтенесе 240 гектар) һәр гектарыннан иң кимендә 16 шар центнер һәм бәрәңгенең гектарыннан кимендә 160 шар центнер уңыш алуга ирешү турында йөкләмә алды. Хәзер без агротехника чараларың комплексын үтәү өстендә эшлибез. Чәчүлек мәйданның барлык участкыларында да кар тоту эшен үткәрәбез. Без быел кырга 500 йөк урнына 1.000 йөк тирес чыгарырга булдык. Колхозчылар һәрбер колхозчы йортыннан 1—2 центнер көл һәм кош тизәге җыярга булдылар.

Бригадада хезмәтне дөрес оештыру зур әһәмиятле мәсьәлә булып тора. Хәзер без эш нормаларын янадан карап чыгабыз. Ким итеп билгеләнгән һәм шулай ук чиктән тыш артык итеп билгеләнгән нормаларны бетерәбез. Нормалар билгеләгәндә иң яхшы колхозчыларыбызның эш тәҗрибәсен нигез итеп алабыз. Мәсәлән, узган елны ике төрәнле сабан белән сөрү нормасы 1,3 гектар иде, хәзер аны 1,5 итеп билгеләдек. Ефремовчылар звеносы оештырырга керештек. Ул 10 кешедән торачак. Аңа 12 гектар җир беркетелә. Звенога житәкчелек итү эшен стахановчы иптәш Бутусовага тапшырдык.

Колхозда агротехниканы өйрәнү түгәрәге эшли. Аңа 32 колхозчы (шуның 12 се минем бригадамнан) йөри. Түгәрәк членнары агротехник иптәш Трофимовның ашламаларны саклау һәм алардан файдалану турындагы, чәчүлек орлыкларның сыйфаты, хезмәтнең учеты һәм башка турыдагы лекцияләрен тыңладылар. Хәзер, агротехника чаралары үткәрүдә ефремовчыларның тәҗрибәсен өйрәнүгә керештеләр.

Безнең бригада тарафыннан алынган йөкләмә үтәләчәк. Минем бригадамда югары уңыш алу өчен көрәштә үзләрен күрсәткән 20 гә якын колхозчы бар. Бригада членнары Павел Бутусов, Петр Калинин, Вера Тарасова, Анастасия Бутусова һәм башка иптәшләр үрнәк рәвештә эшләгәнлекләре өчен берничә тапкыр бүләкләнделәр. Алар хезмәт дисциплинасын күтәрү өчен көрәштә, игеннәрнең уңышын күтәрү өчен көрәштә хәзер дә үрнәк күрсәтәләр.

В. Сидоров.

Столбище районының „Красная Заря“ колхозы бригадиры.

Колхозлар ара ярыш

ШӨГЕР, 11 февраль. (Телефон буенча). Социалистик авыл хуҗалыгы алдынгыларының республика киңәшмәсе билгеләгән бурычларны тормышка ашыру өчен районның алдынгы колхозлары кызу эш алып баралар.

Киңәшмәдә кабул ителгән мөраҗәгатне өйрәнүне оештыру өчен ВКП(б) райкомы колхозларга махсус кешеләр җибәрде. Колхозчылар мөраҗәгатне зур игтибар белән өйрәнәләр, үз колхозларындагы җирле мөмкинлекләрдән чыгып конкрет йөкләмәләр алалар. Мөраҗәгатне өйрәнгәннән соң „Индустрия“ колхозы „Яңа юл“ колхозы белән, „Яшь көч“ колхозы „Алмас“ колхозы белән, „Кызыл Яр“ колхозы „Үзәк“ колхозы белән үзара социалистик ярышка чыктылар.

„Байрак“ колхозы председателе, киңәшмә делегаты иптәш Галиев колхозына кайту белән колхозчыларның гомуми җыелышын чакырды. Киңәшмәдә каралган мәсьәләләр, куелган бурычлар турында колхозчыларга аңлатты, ишеткән тәҗрибәләре турында уртаклашты. Колхозчылар быел үзләрендә югары уңыш алу өчен бөтен шартлар барлыгын әйттеләр. Җыелыш бөртекле культураларның һәр гектарыннан 120 пот уныш алырга сүз бирде һәм „Кызыл Шушма“ колхозын социалистик ярышка чакырды. Иптәш Галиев такдиме буенча 75 центнер минераль ашламалар сатып алырга (план 20 центнер иде) карар бирелде.

Колхозчылар алган йөкләмәләрен практик эш белән ныгыталар. Биредә язгы чәчүгә хәзерлек яхшы. Орлыклар яхшы. Машиналар һәм инвентарьлар хәзер. Җирле ашламалар җыю, агротехника чараларын үткәрү уңышлы бара.

Сафуанов.

Район җир бүлеге мөдире.

КАМА ТАМАГЫ, 10 февраль. (Телефон буенча). Социалистик авыл хуҗалыгы алдынгыларының республика киңәшмәсе мөраҗәгатен районның барлык колхозлары һәм МТС эшчеләре зур игтибар белән тикшерәләр. Мөраҗәгатне тикшерүне оештыру өчен колхозларга район активыннан аерым кешеләр җибәрелде. Районның алдынгы колхозлары язгы чәчүгә хәзерлекне төгәлләделәр. „Парижская Коммуна“, „Кызыл Йолдыз“ колхозлары чәчүгә тулысынча хәзер.

18 нче февральдә авыл хуҗалыгы алдынгылары белән берлектә колхоз җитәкчеләренең район киңәшмәсен үткәрәбез. Бу киңәшмәгә үзебез белән ярышучы Тәтеш районы делегатлары да чакырыла; ике арада төзелгән ярыш договорына кул куелачак.

Ибәтуллин.

Район җир бүлеге мөдире.

„Конфекцион“ артеленең (Казан) чигүче стахановчыларыннан В. С. Яблокова (алдынгы рәттә) һәм Л. П. Грачова иптәшләр. Иптәш Яблокова январь ае планын 202 процентка, иптәш Грачова 154 процентка үтәделәр.

И. Галиев фотосы.

ФЕРГАНӘ ТӘҖРИБӘСЕН—ЮЛЛАР ТӨЗЕЛЕШЕНӘ!

ЯРЫШТА АЛДЫНГЫЛЫК ӨЧЕН

Юлларның яхшы, культуралы булуы һәм һәр вакыт төзек торуы гаят зур әһәмияткә ия булып тора. Безнең Тымытык районында соңгы елларда юл төзелеше буенча шактый зур уңышларга ирешелде. Мөслим—Ютазы, Тымытык—Бөгелмә тракты буенча 40 километр грави һәм таш юллар, 318 пагон метр күперләр төзелде. Ләкин бу уңышлар гына безне канәгатьләндерми әле.

Быел Тымытык районында 30 километр юлга агымдагы ремонт, 5 километр юлга капиталь ремонт, 30 пагон метр күпергә агымдагы ремонт ясалырга, 3 километр яна юл төзелергә тиеш. Бу бурычны уңышлы башкару өчен кыш көне 7 мең кубометр грави һәм 100 кубометр агач материаллары хәзерләнергә һәм алар участкыларга ташылырга тиеш.

Масса-аңлату эшләрен киң җәелдереп, колхозлар белән колхозлар, бригадалар һәм аерым колхозчылар арасында социалистик ярыш методын киң кулланып, без бу эшләрне вактында үтәп чыгарбыз.

Безнең „Коминтерн“ колхозы юл төзелеше планын һәр ел саен арттырып үти. Ләкин Тымытык районы буенча юл төзелеше планы 1939 нчы елны бары 85 процент кына үтәлде. Бу бик зур житешсезлек. Моны быел кабатламаска кирәк.

Без Столбище районының „13 лет Октября“ колхозы членнарының чакыруларын зур күтәренкелек белән каршыладык. „Коминтерн“ колхозы быел юл төзелешенә аеруча зур активлык белән катнашачак.

1940 нчы елның беренче кварталында 300 кубометр грави хәзерләү һәм аны ташу өчен 15 кешедән торган бригада оештырдык. Бу бригадага 15 ат беркетелде. Бригада хәзер ныклы эшкә кереште һәм ул планны 1 нче мартка 100 процент итеп үтәргә социалистик йөкләмә алды. Бригада юл төзелеше планын урып-җыю эшләре башланганчы тулы үтәргә булды.

Без „Коминтерн“ колхозы членнары, 1940 нчы елны юл төзелеше планын срогыннан элек һәм югары сыйфатлы итеп үтәү өчен Мөслим, Ютазы, Бөгелмә, Тымытык һәм Азнакай районнарының барлык колхозларын, юл төзелеше бригадаларын һәм колхозчыларын социалистик ярышка чакырабыз.

„Коминтерн“ колхозы членнары:

Һадиев, Рәхмәтуллин, Сәйфуллин, Ибәтуллин һ. б.

ЮЛ ТӨЗЕЛЕШЕ АЛДЫНГЫЛАРЫ

Саба районының „Кызыл партизан“ колхозы юл төзү буенча районда иң алдынгылар сафына басты. Ул 1939 нчы елны юл төзү планын тулысынча үтәде. Бу колхозда үзенә тапшырылган эшне бик яхшы итеп үтәүче колхозчылар күп. Иптәш Хәмидуллин заданиене 130 процентка үтәде. Тимербаев, Галеев, Гайнуллин бер кубометр таш чыгару урнына 4 кубометр таш чыгардылар. Алар шулай итеп үзләренә тапшырылган заданиене 400 процент итеп үтәделәр.

Алар 1940 нчы елда юл төзү планын үтәү һәм арттырып үтәү өчен районның барлык колхозчыларын социалистик ярышка чакырдылар.

Г. Нагимов.

Район һәм шәһәр советларының башкарма комитетлары председательләренең һәм секретарьларының республика киңәшмәсе

7—9 нчы февральдә Татарстан АССР Совнаркомының утырышлар залында хезмәт ияләре депутатларының район, шәһәр һәм поселкы советларының башкарма комитетлары председательләренең һәм секретарьларының республика киңәшмәсе булды.

Киңәшмәдә, хезмәт ияләре депутатларының җирле Советлары башкарма комитетларының бурычлары һәм 1940 нчы елга район бюджетларының торышы турында инструктив докладлар тыңланды. Беренче мәсьәлә буенча докладны Татарстан АССР Совнаркомы председателе Тынчеров, икенче мәсьәлә буенча Татарстан АССР финанс халык комиссары Шәрәфеев иптәшләр ясадылар.

Хезмәт ияләре депутатларының җирле Советлары, аларның башкарма комитетлары алдында зур һәм катлаулы эш тора. Аерым алганда, быел язгы чәчүгә хәзерлек һәм аны үткәрү буенча советларның башкарма комитетларына зур бурычлар йөкләнә. Тракторларга һәм авыл хуҗалыгы инвентарьларына ремонт, авыл хуҗалыгы кадрларын җитәрлек санда хәзерләү, барлык колхозларны сортлы орлыклар белән, атларны фураж белән тәэмин итү—бу мәсьәләләр барсы да советларның башкарма комитетларының игтибар үзәгендә торырга тиеш.

Политик-культура һәм хуҗалык төзелеше, төзекләндерү, юллар хуҗалыгы, халык мәгарифе һәм сәламәтлек саклау, укый-яза белмәүчелекне бетерү өлкәләрендә советлар алдында зур бурычлар тора. Докладчы иптәш Тынчеров, шулай ук фикер алышуларда катнашучы иптәшләр бу участкыларда ирешелгән уңышлар белән бер рәттән җидди җитешсезлекләр барлыгын күрсәттеләр.

Киңәшмәдә Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы Председателе иптәш Динмөхәметов зур һәм тирән эчтәлекле речь сөйләде. Ул, теземле рәвештә социализмнан коммунизмга күчү чорында хезмәт ияләре депутатларының җирле Советлары алдында торган бурычларга җентекләп тукталды. Иптәш Динмөхәметов җирле Советларның эшендәге җитешсезлекләрне бөтен тулылыгы белән күрсәтте. Җирле Советларның башкарма комитетлары укыйяза белмәүчелекне һәм аз укыйяза белүчелекне бетерү мәсьәләләре белән җитәрлек шөгыльләнмиләр. Республикабызның XX еллыгына укый-яза белмәүчелекне һәм аз укый-яза белүчелекне бетерүне төгәлләргә кирәк. Кинотеатрлар, клублар, уку өйләре, радио һәм башкалар культура учакларына әйләндерелергә тиеш.

Бөртекле культураларның һәр гектарыннан 100 пот уңыш алуга ирешү өчен язгы чәчүгә яхшы хәзерләнергә һәм аны үрнәк рәвештә үткәрергә кирәк. Шунлыктан язгы чәчүгә хәзерлек эше киңәшмәдә катнашучы иптәшләрнең игтибар үзәгендә торды. Фикер алышуларда катнашучылар, чәчүгә хәзерлек эшендәге зур гына җитешсезлекләрне әйтеп, аларны бетерүнең конкрет юлларын күрсәттеләр. Язгы чәчү планын уңышлы итеп үтәү өчен җитәрлек күләмдә яхшы сыйфатлы орлыклар хәзерләргә кирәк. Орлык туплау эше 20 нче февральгә төгәлләнергә тиеш. Ләкин күп кенә районнарда бу мәсьәлә буенча ВКП(б) Өлкә Комитетының VIII нче пленумы карарын тормышка ашыру өчен большевистик көрәш җитәрлек алып барылмый. Байтак районнарда ашлык сугу эше дә төгәлләнмәгән әле. Орлыкларны сортлы орлыкларга алмаштыру эшенең барышы да канәгатьләнерлек түгел.

Агротехника чараларының бөтен комплексын дөрес һәм вактында үткәргәндә генә югары уңышны яулап алырга мөмкин. Без, һава шартлары нинди генә булса да, югары уңыш алырга тиешбез. Моның өчен язны тулы хәзерлек белән каршы алырга һәм язгы чәчүне үрнәк рәвештә үткәрергә кирәк. Тракторларга ремонт 25 нче февральгә төгәлләнергә тиеш, ләкин ремонтның барышы аны вактында төгәлләүне куркыныч астында калдыра.

Юл төзелеше бездә артта калган участкыларның берсе булып тора. Бу әһәмиятле участкыдагы артта калучылыкны бетерергә, юлларны халык хуҗалыгының көннән-көн үсеп бара торган таләпләренә тулысынча җавап бирерлек итәргә кирәк.

Социалистик терлекчелекне үстерү өлкәсендә зур гына җитешсезлекләр барлыгы киңәшмәдә күрсәтелде. Биектау, Дөбъяз һәм башка районнарда фермалар оештыру мәсьәләләренә җитәрлек игтибар бирелми.

Культура төзелеше өлкәсендә дә җитешсезлекләр аз түгел. Мәктәпләрнең, уку өйләренең, клубларның, балалар ясләләренең, мәйданнарының һәм бакчаларының эшенә игтибар җитәрлек түгел. Район оешмалары бу мәсьәләләр белән кирәгенчә шөгыльләнмиләр.

Политик-культура һәм хуҗалык төзелеше өлкәләрендә, партия һәм хөкүмәт директиваларын, совет законнарын үтәүдә, җирле Советларның җитәкчелегендә булган җитешсезлекләр киңәшмәдә большевистик тәнкыйть уты астына алындылар. Киңәшмә эштәге җитешсезлекләрне иң кыска вакыт эчендә бетерү, җирле Советларның башкарма комитетларының эшен алар алдында торган бурычлар югарылыгына күтәрүне тәэмин итү өчен конкрет практик чаралар билгеләде.

В. И. ЛЕНИН ИСМЕНДӘГЕ КӨТЕПХАНӘНЕҢ ЮБИЛЕЕ

10 нчы февральдә В. И. Ленин исемендәге Үзәк көтепханәнең данлыклы 75 еллыгына багышланган тантаналы җыелыш булып үтте. Иптәш Гуревич такдиме буенча, җыелышның президиумына ВКП(б) Өлкә Комитетының бюро составы, Сөләйманов, Контюков, Перов, Зиннуров, Дәүләтшин, Владимиров, Мөхетдинова һәм башка иптәшләр сайланалар.

Тантаналы җыелышка катнашучылар почетлы президиум сайлау турындагы такдимне көчле алкышлар белән каршы алдылар. Почетлы президиумга бөек Сталин һәм аның көрәштәшләре Молотов, Ворошилов, Каганович, Калинин, Андреев, Жданов, Микоян, Хрущев Шверник, Берия, Димитров, Тельман иптәшләр көчле алкышлар астында сайланалар.

В. И. Ленин исемендәге республика Үзәк көтепханәсенең 75 еллыгы турындагы доклад өчен сүз көтепханә директоры иптәш Мөхетдиновага бирелә. Ул үткән тарихи юл һәм алда торган бурычлар турында зур һәм тулы эчтәлекле доклад ясый.

Докладтан соң, Рыжов һәм Фәйзуллина иптәшләр юбилей көннәрендә көтепханә исеменә килгән күп сандагы котлау телеграммаларын укыйлар. Аннары, Воронеж өлкә көтепханәсе вәкиле Дьячкова һәм Мари АССР көтепханәсе вәкиле Виноградов, көтепханәнең актив укучыларыннан Измайлова иптәшләр көтепханә коллективын котлыйлар. Шулай ук, 1919 нчы елда шушы көтепханәгә эшкә кергән һәм хәзерге көндә шәһәр мәгариф бүлегенең көтепханәләр буенча инспекторы иптәш Емельянова үзенең көтепханәдә эшли башлаган көннәрен әйтеп үтә.

Тантаналы җыелыш иптәш Сталинга котлау хатын зур күтәренкелек һәм көчле алкышлар белән кабул итте.

Җыелыштан соң Казан Музыкаль училище укучылары көче белән бик яхшы концерт бирелде.

Р. Б.

1940 нчы елда Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсендә Татарстан АССР павильоны

Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсе колхоз строеның бөек җиңүләренә бөтен халык смотры булып тора. „Безнең күргәзмәбез җиңүләргә йомгак ясап кына калмый, бәлки ул—авыл хуҗалыгын тагын да күтәрүдә, социализмның данлыклы яңа җиңүләренә куәтле чакырудан да гыйбарәт“ (Молотов).

Үткән елны республикабызның авыл хуҗалыгы алдынгыларыннан 5 меңнән артык кеше күргәзмәне карады. Алар социалистик авыл хуҗалыгының стахановчыл тәҗрибәләренең пропагандистлары булып әверелделәр.

Татарстан АССР ның күп кенә колхозлары күргәзмәдәге гаять бай тәҗрибәләрне үзләренә күчерделәр. Һәм шуның нәтиҗәсендә үткән елны иген уңышын күтәрүдә, терлекчелекне үстерүдә яңа уңышларга ирештеләр.

Чаллы районының В. П. Чкалов исемендәге колхозы күргәзмәгә катнашу хокукына ирешү өчен „Яңа Тормыш“ колхозы белән ярышып, үткән елны арышның һәр гектарыннан уртача 13,5 центнер, тарының һәр гектарыннан 14,5 центнер, борчакның һәр гектарыннан 14 центнер, солының һәр гектарыннан 21 центнер һәм бодайның һәр гектарыннан уртача 20 центнер иген уңышы алуга иреште.

Әлмәт районының „Туры Юл“ колхозы правлениесе күргәзмәдә терлекчелек һәм бакчачылык тәҗрибәләре белән танышканнан соң үткән елны атларның нәселен яхшырту өчен яхшы нәселле айгыр сатып алды, дуңгыз асрау фермасы һәм җимеш бакчасы оештырды.

Норлат районы, „Активист“ колхозы членнары, хата-лаборатория мөдире иптәш Хәялиев инициативасы белән басуларны ашлау өчен торф хәзерләделәр, Мичурин сортлы алма бакчасы һәм һәр төрле тәҗрибә участкылары оештырдылар.

Социалистик авыл хуҗалыгының стахановчыл методларын үз колхозларына күчерүдә күргәзмә экскурсантларының актив ролен күрсәтүче шундый мисальләрне бик күпләп санарга мөмкин.

Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсендә Татарстан АССР павильоны үткән елдагыга чагыштырганда һәр яктан күп тапкыр баерак булачак.

Павильонның 1940 нчы елгы тематик-экспозицион планын төзегәндә без үткән елны күргәзмә Баш Комитеты тарафыннан, республикабызның җитәкчеләре тарафыннан һәм павильонны караган аерым кешеләр тарафыннан ясалган күрсәтмәләрне һәм киңәшләрне быел тулысынча исәпкә алып эш иттек.

Шуның өстенә безнең павильоныбыз быел Татарстан АССР ның XX еллыгын да чагылдырачак.

Павильонга кергәч тә алгы залда „Казан губернасының элеккеге хәле“ стендында 1917 нче елга кадәр хәерчелек һәм халык михнәте крае сыйфатында күрсәтелгән Казан губернасы белән бер рәттән яңа стенд—„Казанда һәм Казан губернасында Октябрь Социалистик революциясе“ стенде оештырыла. Бу стенд түбәндәге темаларга кул белән эшләнгән картиналардан һәм репродуктив фотокартиналардан торачак:

1. „1917 нче елның октябрендә Казан эшчеләренең 10 мең кешелек митингысы“.

2. „1917 нче елның 24 нче октябрендә артиллеристларның юнкерларга каршы сугышы“.

3. „1917 нче елның 24 нче октябрендә Елга арьягы эшчеләренең чыгышы“.

4. „1918 нче елда Казан янында матрослар десанты“.

Шул ук стендта 1918 нче елда чехлардан — учредилкачылардан Казанны коткарган сугышчыларга һәм командирларга Совнарком председателе В. И. Лениннең котлау телеграммасы куелачак.

Икенче стенд—„Казан—В. И. Ленин, В. М. Молотов, С. М. Киров, Я. М. Свердлов, Н. Э. Бауманның уку һәм революцион эш урны“, Владимир Ильич Лениннең беренче сөргенгә җибәрелгән урны булу ягыннан Кукушкино авылын да күрсәтү белән тулыландырыла.

„Сталин Конституциясе“ стендында Татарстан АССР ның ничек алга китүе, Социалистик Октябрь революциясенә кадәр хәерче һәм ач булган бер өлкәдән орденлы республикага, индустриаль-аграр илгә, һәр яктан чәчәк атучы илгә әйләнүе үткән елдагыдан күп тапкыр тулырак күрсәтеләчәк.

Икенче залда Татарстан АССР ның социалистик терлекчелеге күрсәтеләчәк.

„Авыл хуҗалыгы“ һәм „Терлекчелек“ стендларында республикада иген уңышын күтәрү һәм терлекчелекне үстерүне тәэмин итү өчен үткәрелгән төп агротехника һәм зоотехника чараларына киң урын биреләчәк.

Өченче төп залның стендлары республиканың иң яхшы хуҗалыкларын киңәйтелгән тәртиптә күрсәтүгә багышлана. Бу залда Әтнә районының Киров исемендәге колхозы, Актаныш МТС ы, Буа районының Каганович исемендәге колхозы, Норлат районының „Активист“ колхозы күрсәтеләчәк.

„Татарстан АССР җимеш һәм яшелчә муллыгы юлында“ исемле стендта павильон Минзәлә районының „Дружба“ колхозын бирәчәк. Бу колхоз республикабызның көнчыгыш районнарында җимеш бакчачылыгын җәелдерү буенча пионер булып тора.

Шул стендның икенче өлешендә яшелчәчелек буенча зур уңышларга ирешкән „Память Ленина“ колхозының (Столбище районы) хата-лабораториясенә урын биреләчәк.

„Колхозларда социалистик терлекчелек“ стенде быел үткән елдагыга чагыштырганда шактый тулырак, киңрәк булачак. Биредә Норлат районы, Ленин исемендәге колхозның товарлыклы-сөтчелек фермасы, Теләче районы, „Марс №2“ колхозының сарык асраучылык фермасы, „Путь Ленина“ колхозының ат асраучылык фермасы күрсәтеләчәк.

Экспонентларны киңәйтелгән тәртиптә күрсәткәндә быел төп игтибарны аларның эш методларын чагылдыруга бирәчәкбез.

4 нче залда халык мәгарифе, авыл хуҗалыгы фәне һәм фән кешеләренең эше күрсәтеләчәк. Бу залда 1910 нчы елда патша хөкүмәте тарафыннан Казан губернасында халык мәгарифе эшләренә бары 310 мең сум акча тотылуы, ә Татарстан АССР да исә тик 1938 нче елда гына да халык мәгарифе эшенә 179 миллион сумнан артык акча тотылуы чагылдырылачак.

Шул ук залда Казан фәнни-тикшеренү ветеринария институтының эшенә һәм Казан селекция станциясе эшенә зур урын бирелә.

Павильонның иң соңгы (бишенче) залында Октябрь Социалистик революциясенә кадәр татар хатын-кызларының караңгылыкта, коллыкта яшәүләре, ә хәзер исә тулы хокуклы кешеләргә, коммунистик җәмгыять төзүдә актив катнашучыларга әйләнүләре чагылдырылачак.

Татарстан АССР да халык иҗады һәм Совет матбугаты павильонда быел күп тапкыр тулырак итеп биреләчәк.

„Өченче бишьеллыкта Татарстан АССР ның чәчәк атуы“ стенде быел аеруча матур һәм кызыклы итеп оештырыла. Без биредә зур картада республикабызның промышленностен, транспортын, бик күп төрле җир асты байлыкларын һәм ул байлыклардан өченче бишьеллык башында һәм өченче бишьеллык ахрында ничек файдаланылуын күрсәтәчәкбез. Татарстан АССР ның өченче бишьеллык планы буенча болардан башка төп мәсьәләләрне яктыртуга бу стендның сул һәм уң як өлешләрендә урын бирелә.

Үткән елны натураль экспонатларның аз булуы безнең павильоныбызның төп кимчелекләреннән берсе иде. Без быел бу кимчелекне бетерәбез, павильонның барлык зал һәм стендларын натураль экспонатлар белән тулыландырачакбыз.

Н. Вагапов.

Татарстан АССР павильоны директоры.

СОВЕТ ТЕАТРЫНЫҢ КҮРЕНЕКЛЕ МАСТЕРЫ

12 нче февральдә күренекле сәхнә мастеры—СССР ның халык артисты Василий Иванович Качаловның тууына 65 ел тулды. Аның художество театрында беренче чыгышына шушы елның көзендә 40 ел тула. „Снегурочка" спектаклендә Качаловның Берендей ролен зур уңыш белән башкаруы бу күренекле актерның алдагы юлын тәмам ачыкландырды.

Качалов бу театрда 50 дән артык роль уйнады. Аларның һәр кайсы ачык образны күрсәтә һәм геройның тирән эчтәлеген ача.

В. И. Качаловның 60 еллыгы уңае белән хөкүмәт аны Хезмәт Кызыл байрагы ордены белән бүләкләгәч ул, радио буенча сөйләгән речендә болай диде:

„60 ел. Мин үз җилкәмдә ул йөкне сизмим. Минем иҗад итәсем, эшлисем һәм театрда яңа образлар тудырасым килә... Мин үземдә иҗад көчләре артканны хис итәм һәм кайгырма, карт, син яши торган һәм эшли торган илдә 60 яшь куркыныч түгел дип әйтәсем килә!".

Василий Иванович бу сүзләрен армый-талмый тормышка ашыра.

Хәзер В. И. Качалов Чеховның „Өч туган кыз" исемле пьессасында Вершинин ролендә уйнарга хәзерләнә һәм „Горе от ума" пьессасындагы Фамусов образы өстендә эшли. (ТАСС).

МӘКТӘП ҺӘМ МУЗЕЙ

1939 нчы елда Татарстанның Крайны Өйрәнү Үзәк Музеенда 130 меңгә якын кеше булды. Шуларның 49.590 ы укучы балалар. 1938 нче ел белән чагыштырганда укучы балаларның музейгә йөрүләре ике тапкыр артты. Бу хәл укучы балаларның, педагогларның музей белән кызыксынуларын һәм музейнең дә бу өлкәдә оешкан рәвештә эш башлавын күрсәтә.

Үзенең 45 ел яшәү дәверендә крайны өйрәнүдә бик бай материаллар, экспонатлар җыйды. Бу материаллар мәктәп өчен бик әһәмиятлеләр. Уку программасы буенча үтелгәннәрне практика белән бәйләүдә музейнең экспонатлары зур роль уйныйлар. Музейдә крайның табигатен күрсәткән бүлек бар. Мәктәпләрнең сорауларын искә алып Казан профессорларыннан Ливанов, Баранов, Чердынцев һәм башкаларның ярдәме белән 1938 нче елда музейдә „Кереш бүлек" оештырылды. Бу бүлектә җирнең барлыкка килүе һәм тарихы, җирдә тереклекнең башлануы һәм үсеше, кешенең барлыкка килүе, дарвинизм һәм башка темалар яктыртыла.

Музейнең тарих бүлеге укучылар арасында аеруча зур популярлек белән файдалана. Бу бүлек аеруча җирле материалларга бай. Анда Болгар дәүләте турында коллекцияләр тупланган. Мәктәпләргә булышлык күрсәтү йөзеннән музей хәзер СССР халыкларының тарихларын күрсәткән аерым вакыйгаларне чагылдыручы күп кенә яңа темалар өстендә эшли. Яңа уку елына кадәр бу эш нигездә тәгәлләнәчәк.

Күп кенә педагоглар, мәсәлән, Магницкий, Борһан, Хангильдина, Кокушкина, Ощенкова, Разумовская һәм башкалар үзләренең укыту эшләрендә музейдән тәртипле рәвештә файдаланалар. Мәктәпләрдә каникул вакытларында балаларны музейгә китерү өчен күп кенә эшләр башкарылды. Болардан тыш балалар өчен „Авиация элек һәм хәзер", „Зур Волга", „Таяктан тракторга", „Чарльз Дарвин", „Гасырларга экскурсия" (Болгар янында алып барылган археологик казулар) һәм башка темаларда лекцияләр үткәрелде. Музей янында яшь геологлар, яшь тарихчылар һәм яшь художникларның түгәрәкләре эшләде.

Ата-аналар арасында эшләү буенча да башлангыч эшләр үткәрелде. Музейдә ата-аналар өчен РСФСР Верховный Советы депутаты профессор Агафоновның, „Балаларда йогышлы аурулар" дигән темада лекциясе оештырылды.

Югарыда саналганнар, музейнең мәктәпләргә ярдәм күрсәтү буенча зур эш эшли алуын күрсәтәләр. Болар әле беренче адымнар гына. Бу эшне киләчәктә тагын да җәелдерү өчен бөтен мөмкинлекләр бар. Татарстан Мәгариф Халык Комиссариаты һәм шәһәр мәгариф бүлеге бу файдалы эш участкысына аеруча әһәмият бирергә тиешләр.

В. Дьяконов.

ТАТАРСТАННЫҢ ИҢ ЯХШЫ КРОЛИК ФЕРМАСЫ

Арча районы, Тельман исемендәге колхозның кролик асраучылык фермасы 1940 нчы елны Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсенә катнашу өчен кандидат итеп расланды. Фермада 350 баш ана кролик исәпләнә. Соңгы ике ел эчендә һәрбер ана кроликтан уртача 17,5 баш үрчем алынды.

Ферма алдынгыларыннан Әһлиева, Сәләхиева, Әдһәмов, Әдһәмова һәм Нургалиев иптәшләр 1940 нчы елны Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсенә катнашу өчен кандидат итеп расландылар.

Дозорда (СССР ның көнбатыш чиге). Д. Чернов фото-этюды.

КЫЗЫЛ АРМИЯНЕҢ ҺӘМ ХӘРБИ ДИҢГЕЗ ФЛОТЫНЫҢ XXII ЕЛЛЫГЫ АЛДЫННАН

ДОПРИЗЫВНИКЛАР БӘЙРӘМГӘ ХӘЗЕРЛӘНӘЛӘР

Буденный районында 1920-21 нче елда туган допризывникларның район киңәшмәсе булып үтте. Киңәшмәдә катнашучылар 1940 нчы елгы призывка һәм XXII еллык юбилейгә хәзерлек буенча үз өсләренә йөкләмәләр алдылар һәм Чүпрәле районы допризывникларын социалистик ярышка чакырдылар.

Тимбай авылының тулы булмаган урта мәктәбе укытучысы иптәш Исланов Кызыл Армия көненә ПВХО буенча 30 значкист хәзерләп чыгару өчен көрәшә. Яңа Тинчәле авылы допризывникларыннан Фәтхуллов һәм Гыйбадуллин иптәшләр „Ворошиловча атучы" значогына норма тапшырдылар.

Осоавиахимның башлангыч оешмалары чаңгы походлары үткәрәләр. Чув. Кищак авылы тулы булмаган урта мәктәбе укучылары комсомолец иптәш Фадеев җитәкчелегендә 13 километр дистанциядә чаңгы походы үткәрделәр. Иске Шәйморза авылы допризывникларыннан 16 кеше противогазларда хәрбиләштерелгән походка чыктылар. XXII еллыкка хәзерлек уңае белән районның допризывниклары ике район арасында төзелгән социалистик ярыш договорының үтәлешен тикшерү өчен Чүпрәле районына поход оештырачаклар.

Партия райкомының хәрби бүлеге һәм Осоавиахимның район советы башлангыч оешма председательләре өчен район үзәгендә 5 көнлек семинар үткәрделәр.

Районның барлык колхозларында Кызыл Армиянең героик юлы, аны оештыручылар турында беседалар алып барыла. Бу эштә хезмәт ияләре депутатларының җирле Советларына сайлауларда агитатор булып эшләгән иптәшләр зур активлык күрсәтәләр.

А. Я.

ГИДУВТА ЗНАЧКИСТЛАР ХӘЗЕРЛӘҮ

Врачларның белемнәрен күтәрү институтының фәнни работникларыннан, врачларыннан, урта һәм кече медперсоналларыннан 230 кеше ПВХО значогына норма тапшыруны уңышлы рәвештә тәмам иттеләр.

Значкистлар арасында профессорлардан И. И. Русецкий, Л. М. Рахлин, М. В. Троицкий, Э. Ф. Ротермель, Н. Н. Лозанов, врач ординаторлардан Лифшиц, Гайнанова, доцент Осиповский, ассистент Персианинов иптәшләр бар.

ЮТАЗЫ РАЙОНЫНДА

Бәйрәкә авылындагы урта мәктәптә Кызыл Хач җәмгыятенең башлангыч оешмасы төзелде. Аңа укучылардан һәм укытучылардан 80 кеше член булып керделәр. Алардан 61 кеше инде „ГСО" значогына норма тапшырдылар.

Осоавиахимның колхоздагы башлангыч оешмасы янында күп кенә оборона түгәрәкләре эшли. Ворошиловча атучылар түгәрәгенә 30 кеше, ПВХО түгәрәгенә 80 кеше йөри.

ГАЗЕТАЛАРДАН

„ТИХИЙ ДОН" РОМАНЫ ЯЗЫЛЫП БЕТТЕ

Орденлы язучы М. Шолохов шушы көннәрдә „Художество әдәбияты" издательствосына „Тихий Дон" романының соңгы ике бүлеген (7 нче һәм 8 нче бүлекләрен) тапшырды. 7 нче һәм 8 нче бүлекләр романның дүртенче китабын тәшкил итәләр. Бу дүртенче китапның аерым бүлекләре газета һәм журналларда басылганнар иде. 7 нче бүлек 1938 нче елда „Роман-газета"да басылган иде.

„Тихий Дон" романының дүртенче китабы якын көннәрдә наборга бирелә. Ул ашыгыч рәвештә һәм күп тиражда басылып чыгачак. Шулай ук китапның массовый сериясен чыгару да күздә тотыла. Романның 8 нче бүлеге „Роман-газета" басмаларының берсендә басылачак. „Известия".

1941 НЧЕ ЕЛДА БУЛАЧАК КОЯШ ТОТЫЛУНЫ КҮЗӘТҮГӘ ХӘЗЕРЛЕК

СССР Фәннәр Академиясенең комиссиясе 1941 нче елда булачак кояш тотылуны күзәтүгә Полково обсерваториясендә хәзерлек эшләре башлады. Маглүм ки, 1941 нче елда кояш тотылу СССР да Арал диңгезеннән алып Алма-Атага кадәр булган территориядә күренәчәк. Булачак күзәтүләр районы махсус ике экспедиция тарафыннан тикшерелде һәм һаваның торышы турында кирәкле маглүматлар алынды.

Хәзер күзәтү өчен кирәк булган приборлар һәм аппаратлар хәзерләнә. „Правда".

4 НЧЕ ЯСАЛМА КАУЧУК ЗАВОДЫ ЭШЧЕЛӘРЕ ӨЧЕН КЛУБ

Быел 4 нче ясалма каучук заводы эшчеләре өчен клуб төзелә. Клуб Павлюхин урамына, хәзерге вакытта Горзеленстрой карамагында булган участкыга салыначак.

4 нче номерлы ясалма каучук заводы клубы Казан шәһәрендәге иң матур һәм иң зур клубларның берсе булачак. Аны төзүгә 3 миллион сум акча билгеләнде. Бинаның тулай кубатурасы—28 мең кубометр. Клубта 700 кеше сыешлы тамаша залы, 300 кеше сыешлы утырышлар залы, физкультура залы, кафе-ашханә, пионерлар һәм балалар бүлмәләре, түгәрәк занятиеләре өчен бүлмәләр һәм башкалар булачак.

Клуб 1941 нче алның 1 нче яртысында төзелеп бетәргә тиеш.

ТАТГОСФИЛАРМОНИЯ

Кызыл Армия йортында 12 нче февральдә (талон 38) | Дәүләт циркында 14 нче февральдә (талон 39)

ДОН КАЗАКЛАРЫНЫҢ ҖЫРЛАРЫ ҺӘМ БИЮЛӘРЕ АНСАМБЛЕ

Художество бүлеге мөдире, баш дирижер Д. А. Колонийцев.
Репертуарда: Совет композиторларының әсәрләре, казак халык җырлары һәм казак биюләре.
Касса Кызыл Армия йортында һәр көн һәм Дәүләт циркында көндез 3 сәгаттән кич 9 га кадәр ачык.
Концертлар Кызыл Армия йортында кич 9 да, Дәүләт циркында кич 8 дә башлана.

ЗУР ДРАМА ТЕАТРЫ

12 нче февральдә көндез
МАСКАРАД (талон 20)
кич
КУРКЫНЫЧЛЫ БОРЫЛЫШ (талон 99),
14 һәм 15 нче февральдә
МАСКАРАД
Спектакльләр кич 7 сәгат 30 минутта башлана. Билетлар көндез 11 сәгат 30 минуттан 2 гә һәм кич 5 сәгаттән 7 сәгат 30 минутка кадәр кассада сатыла.

ЗУР ТЕАТР ФИЛИАЛЫ

(Киров районы Культура сарае)
Бүген, 12 нче февральдә көндез һәм кич
БАКЧАЛАР ЧӘЧӘК АТА
Талоннар: көндез 49, 50 һәм кич 51, 52,
Спектакльләр көндез 12 сәгаттә, кич 8 дә башлана.

ДӘҮЛӘТ ЦИРКЫ

БҮГЕН ҺӘМ ҺӘР КӨН
Тулысынча яңа программа
ПОПУЛЯР КОМИК, ҺӘР ТӨРЛЕ ХАЙВАННАРНЫ ӨЙРӘТҮЧЕ,
РСФСР ның атказанган артисты, орденлы
М. ЗОЛЛО үзенең антропозоологик труппасы белән.
12 нче февральдә көндез 12 сәгаттә
М. ЗОЛЛО катнашы белән зур цирк уены.
Касса һәр көн көндез 11 сәгаттән 1 гә һәм кич 5 тән 9 га кадәр ачык.

Галиәсгар Камал исемендәге
Татар Дәүләт Академия театры
12 нче февральдә көндез 12 сәгаттә һәм кич
ТУКАЙ
Талоннар: көндез 113, кич 114.
13 һәм 14 нче февральдә
БУЛАК АРТЫ „РЕСПУБЛИКАСЫ"
Талоннар: 115 һәм 116.
Спектакльләр кич 7 сәгат 30 минутта башлана.
Касса һәр көн көндез 11 сәгаттән 2 гә һәм кич 5 сәгаттән 9га кадәр ачык. ТДАТ.

Татар Дәүләт Опера театры
Татар Дәүләт Академия театры бинасында.
15 нче февральдә (талон 78).
КАЧКЫН
Кич 7 сәгат 30 минутта башлана.
Культпоходлар оештыру буенча заявкалар алына.
Телефоннар: 29—04 һәм 30—78.

БҮГЕН КИНОЛАРДА

„Электро" 12, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да,	ФУТЛЯРДАГЫ КЕШЕ
„Унион" 11, 1-20, 3-40, 6, 8-20, 10-30 да.	МИНИН ҺӘМ ПОЖАРСКИЙ
„Кызыл Йолдыз" 12, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да	КОМСОМОЛЬСК
„Колхозник" 4, 6, 8 һәм 10 да.	11 нче ИЮЛЬ
„Чаткы" 6, 8 һәм 10 да.	КАЙНАР КӨННӘР
„Пионер" 10, 11-20, 1, 2, 3-30, 5-30, 7-10, 8-50, 10-30 да.	Көндезге һәм кичке сеансларда ПАТРИОТ Көндез 1 сәгаттә мәктәпкә кадәр яштәге балалар өчен сеанс.
„Рот-Фронт" 4, 6, 8, 10 да.	ЗАПОРОЖЕЦ ЗА ДУНАЕМ
Культура сарае 5, 7, 9 да.	УКЫТУЧЫ

А. М. ГОРЬКИЙ МУЗЕЕ
бөек пролетар язучы Горький әсәрләрен һәм язучы турында критик әдәбият
САТЫП АЛА
Казан, Кече Галактионов урамы, 24. 255—2—1

КИРӘК:

Архитектура-Планлаштыру мастерскаясына дайми эшкә НОРМАЛАУЧЫ-ПЛАНОВИК. Казан, Чернышевский урамы, 1, өченче кат, 36 нчы бүлмә. 220—3—1

14 нче трестның 4 нче Төзелеш конторасына, ТӨЗЕЛЕШ ЭШЛӘРЕ БУЕНЧА ЮГАРЫ КВАЛИФИКАЦИЯЛЕ ПРОРАБЛАР һәм ДЕСЯТНИКЛАР. Телефон Промрайон коммутаторы, 1. 264—2—1

„Трансэнергокадр" ның Казан бүлегенә технорук булып эшләү өчен, АВТО ЭШЛӘРЕ БУЕНЧА ИНЖЕНЕР һәм ИНСТРУКТОР БУЛЫП ЭШЛӘҮ ӨЧЕН ТЕХНИК-ЭЛЕКТРИКЛАР һәм ТЕПЛОТЕХНИКЛАР. Казан, Банк урамы, 15. 263—2—1

„Главмука" ның Татарстан трестына (Казан, Бауман урамы 35/12) ЭЛЕКТРОМЕХАНИКЛАР, БАШ БУХГАЛТЕРЛАР, ШОФЕРЛАР, МАШИНИСТКАЛАР, ҖИТЕШТЕРҮ ЭШЛӘРЕ БУЕНЧА АГЕНТ, пар машиналары һәм „Дизель" двигательләре буенча МЕХАНИКЛАР. 259—2—1

4 нче номер тегерменгә БАШ МЕХАНИК, МОТОРЧЫЛАР, БӨРТЕКЛЕ АШЛЫК һәм ОН КАБУЛ ИТҮЧЕЛӘР, ГРУЗЧИКЛАР, ҖЫЕШТЫРУЧЫЛАР, бөртекле ашлык һәм он складлары өчен МӨДИРЛӘР. Ярминкә урамы, 20. 271—1

Татпромпроектка, эш башыннан эшләү өчен, проектлаштыру эше буенча кимендә 3 еллык стажлы ПРОЕКТЛАШТЫРУЧЫ-ТӨЗҮЧЕ-РАСЧЕТЧЫ ИНЖЕНЕРЛАР. Татпромпроектка килергә. Казан, Татарстан һәм Комсомол урамнары чаты, 17/2. 269—2—1

ФӘН ДӨНЬЯСЫ ӨЧЕН ЗУР ХӘЗИНӘ

1893—96 нчы елларны атаклы галим Фритиоф Нансен үзенең „Фрам" исемле карабында Төньяк Боз океанында булган иде. Ул Көнбатыш киңлегенең 85 градус 56 минутында булды.

1937 нче елның 23 нче октябрендә Лаптев диңгезеннән үзенең хәрәкәтен башлаган „Седов" бозваткычы „Фрам" ның хәрәкәт итү юлыннан байтак көнбатышта булды.

Нансен көнбатыш котып турында бик кыйммәтле материаллар ала алды һәм Арктиканы тикшерүдә аның фәнни хезмәтләре күп еллар буена беренче чыганак булып хезмәт иттеләр. Хәзерге көндә дә Ф. Нансенның материаллары тарихи документ кына булып калмыйча, фәнни әһәмияте ягыннан да бик зур урынны тоталар. Дөрес, Нансеннан башка да күп кенә экспедицияләр төзелде. Ләкин алар фәнни яктан ул кадәр кыйммәтле материал бирә алмадылар.

Ф. Нансенның котыпта фәнни экспедиция төзеп калдыру уе тик безнең илебездә—фән һәм техникага үсәргә тулы мөмкинлек булган Советлар илендә генә тормышка ашырылды.

Папанинчылар эпопеясе бөтен дөньяны таңга калдырды һәм бездә фәннең нинди зур дәрәҗәдә үсүен, фәнне тагын да үстерергә нинди мөмкинлекләр булуны ачык күрсәтте. Папанинчылар экспедициясе 9 ай буе боз өстендә хәрәкәт итү нәтиҗәсендә гидрологиягә, геофизикага, биологиягә, бигрәк тә метеорологиягә һәм башка фәннәргә кирәк булган бик күп материалларны туплады һәм бу фәннәрнең алга китүенә бик зур хезмәт күрсәтте. Хәзерге көндә безнең караваннар боз диңгезе яры буйлап ерак көнчыгышка меңнәрчә тонналап товарлар илтәләр. Ләкин бу карваннарның юллары уңышлы чыксын өчен Боз океанының гидро-метеорология режимнарын системалы рәвештә ныклап өйрәнергә, тикшерергә кирәк. Без хәзер Баренц, Кара диңгезләренең һәм башка диңгезләрнең үзәк котып бассейны белән нык бәйләнештә икәнлеген яхшы беләбез.

Безнең карваннарның юлы Лаптев, Баренц диңгезләреннән һәм башка диңгезләрдән үткәнлектән, бу диңгезләрнең бозлы яки бозсыз булулары алдан ук, ягъни карваннар юлга чыкканчы ук, дөрес итеп билгеләргә мөмкин.

Седовчылар фән өчен гаять зур һәм бай материал җыйнадылар. Боз океанында җилләр, сувыклар һәм бозлар белән көрәштә аларның җиңеп чыгулары безнең күп миллионлы совет халкы өчен зур куаныч.

Седовчылар Арктиканың үзәк өлеше булган Лаптев диңгезеннән алып, Гренландия диңгезенә кадәр булган зур бассейнны ныклы рәвештә тикшерделәр һәм түбәндәге нәтиҗәләргә килделәр.

1. „Седов" экспедициясенең эше нәтиҗәсендә, материк сайлыгының Лаптев диңгезендәге чиге маглүм булды.

2. „Седов" экспедициясе диңгез төбен 3.000 метрдан артыграк тирәнлектә нак 30 тапкыр үлчәде. Шунсы кызык; бу экспедиция Франц Иосиф җиреннән көнбатыштарак урында диңгез тирәнлегенең 5.000 метр икәнлеген ачты. Мәсәлән, седовчылар 86 градус 37 минут киңлектә һәм 45 градус 5 минут озынлыкта диңгезнең тирәнлеген үлчәделәр. Тирәнлек 4.952 метр булды. 86 градус 23,5 минут киңлектә һәм 38 градус 25 минут озынлыкта диңгез тирәнлеге 4.980 метр булды. Моңарчы билгеле булган тирәнлек 3.850 метр (Нансен тарафыннан үлчәнгән) һәм 4.395 метр (папанинчылар тарафыннан үлчәнгән) дип исәпләнә иде.

3. „Седов" экспедициясенең иң әһәмиятле һәм кыйммәтле эше—метеорологик үлчәү. Седовчылар диңгез тирәнлеген барлыгы 5.000 тапкыр үлчәделәр. Һаваның үзгәрешен алдан әйтүгә, бозларның күчеп йөрүләрен алдан ук билгеләргә кирәкле булган материаллар бирделәр. Метеорологик үлчәнешләрнең кыйммәте шунда: аларның нинди урында алынганлыклары маглүм һәм бу бик әһәмиятле. Седовчылар йолдызларга карап үзләренең кай җирдә торганлыкларын һәр вакыт билгеләп бардылар.

4. Ф. Нансен үзенең экспедициясендә Атлантик океаннан Боз океанына суның җылы агымы керүен әйтеп үткән иде. Седовчылар бу җылы агымның 1937—1939 нчы елгы температурасы 1893—1896 нчы елгы температурадан югарырак икәнлекне расладылар. Әгәр дә „Фрам" һәм „Седов" ның йөзү тизлекләрен чагыштырып карасак, чыннан да Атлантик океаныннан җылы агым Боз океанына юнәлә. Ә Боз океаныннан Атлантик океанга Шпицберген белән Гренландия арасыннан бозлар агып чыкканлыкны күрәбез.

5. Седовчылар 60 урында җир магниты элементларының үзгәрешләрен тикшерделәр. Тикшерү маглүматлары Боз океанының үзәк басейнындагы магнит картасын төзегәндә бик әһәмиятле материал булып торачаклар.

6. Седовчыларның 6 нчы эше—киңлеккә һәм югарылыкка карап, ягъни котыпка якынаюга яки котыптан ерагаюга карап җирнең авырлык тарту көче үзгәрешен үлчәү.

7. Югары геодезия алдына җир шарының фигурасын билгеләү мәсьәләсе куела. Бу мәсьәләне хәл итүдә седовчыларның уңышлы эш алып баруларын әйтеп китәргә кирәк. Бу мәсьәләне, югарыда әйтелгәнчә, җирнең авырлыкны тарту көченең үзгәрүенә карап хәл итәргә мөмкин. Седовчыларның юлы котып өлкәсеннән көньяк-көнчыгышка таба үзгәрешсез дәвам итте дип һич тә әйтеп булмый. Чөнки аларның юлы төрле якка үзгәреп, кай вакытларда алар хәтта кирегә таба да хәрәкәт иттеләр. Ләкин гомумән алганда аларның юлы көньяк-көнчыгышка таба булды. Урындагы җилләрнең тәэсире турында Ф. Нансен үз вактында ике кагыйдә биргән иде. Беренчесе—югары киңлектә бозлар җилгә караганда 50 тапкыр акрынрак баралар. Икенчесе—бозларның хәрәкәте җил юнәлешеннән уңга таба 30—40 градуска авыша. Бу икенчесе җир шарының әйләнү көченең тәэсир итүе нәтиҗәсендә килеп чыга.

Дөрес, бу кагыйдәләр ярдан ерак булган бик зур боз кисәкләре эчендә һәм диңгез агымы булмаган урыннарда гына туры килә. „Седов"ның шундый шартларда хәрәкәт итүе Ф. Нансен кагыйдәләрен тагын бер кат тикшереп расларга мөмкинлек бирде.

Седовчылар үзләренә йөкләнгән бурычны чын геройларча башкарып чыктылар. Седовчыларның зур сабырлык белән үзләрен аямыйча эшләүләре фән дөньясы өчен искиткеч гүзәл хәзинәләр яулап алырга мөмкинлек бирде. Алар туган ил ярларыннан ерак булсалар да, Советлар иленең, партиянең, хөкүмәтнең, иптәш Сталинның үзенең аларны бер генә минутка да онытмауларын, аларга һәр вакыт игтибар бирүләрен бик яхшы белеп тордылар.

Седовчыларның җиңүе—ул бөтен совет халкының җиңүе, патриотлык үрнәге. Бу җиңү, Сталин эпохасында фәннең чәчәк атуы өчен совет кешеләренең һәр нәрсәне эшләргә хәзер торуларын күрсәтә.

Х. Гобәйдуллин.
КХТИ ның физика кафедрасы ассистенты.

ТӨРЛЕ ХӘБӘРЛӘР

■ 11 нче февральдә Ленинградта дәүләтнең 1938 нче елгы эчке заемының 10 нчы тиражы булачак. Тиражда 7668.800 сумлык 11.360 отыш уйналачак. Отышлар арасында—25 мең сумлык 8 отыш, 10 мең сумлык 40 отыш һәм 5 мең сумлык 240 отыш булачак.

■ Февраль аенда СССР Фәннәр Академиясе академик А. Е. Фаворскийның тууына 80 ел һәм фәнни педагогия эшенә 55 ел тулуны билгеләп үтә. А. Е. Фаворский—органик химия өлкәсендә күренекле галим һәм тикшеренүче. Академик Фаворский югары уку йортларының органик химия кафедраларына 50 елдан артык җитәкчелек итте. Хәзер ул СССР Фәннәр Академиясенең органик химия институтының берничә фәнни тикшеренү лабораториясе эшенә җитәкчелек итә.

■ Юнайтед Пресс агентлыгының хәбәр итүенә караганда, адмирал Бэрд „Бир" экспедициясе судносы экспедициянең 33 членын Кече Америкада җиргә төшергәнлекне һәм аларның анда 14 ай булачакларын Вашингтонга радио буенча хәбәр иткән. Экспедициянең суднода калган членнары, шул исәптән Бэрд үзе беренчесеннән мең миль ераклыкта икенче база оештырырга уйлыйлар.

13 нче февраль, кич 6 сәгаттә Партия Мәгарифе йортында, „Партиянең VI нчы съезды" дигән темада комсомолның Шәһәр активы өчен лекция була. Лектор иптәш ГРОМОВ.

Җаваплы редактор
һ. АБДРАХМАНОВ.
Ответ. редактор Х. АБДРАХМАНОВ.